Роналдуга каршы тора алмадык

«Роналду тубы кертелүгә гаепнең 80 проценты минем өстә», – дигән капкачы Акинфеев. Бу аның ил җыелмасы өчен йөзенче матчы булган. Россия тренеры Станислав Черчесов сүзләренчә, әлеге уенда команда үз алдына куйган максат-бурычларны тулысынча үтәгән.

Шимбә көнне Россияне чираттагы көндәше – Мексика уенчылары көтә. Матч 18.00 сәгатьтә башлана. Бу безнекеләр өчен хәлиткеч уен булачак.

7 БИТ

Газетага язылу 2017 елның 29 июненә кадәр дәвам итә

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 23.06.2017 | №67 (5829)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КҮРШЕ РЕСПУБЛИКА ФЕРМЕРЛАРЫ БЕЗДӘН НИК КӨНЛӘШӘ?

Россия авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре, соңгы биш ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, узган елгы сезонны иң уңышлысы дип санаган. Ә 2016 елда уздырылган сораштырулар вакытында фермерлар, 2015 елны иң уңышлысы, дигән булган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

sntat.ru

Әлеге сораштыруларны авыл хуҗалыгы тармагында дөньяның әйдәп баручы «Сингента» компаниясе уздырган. Компаниянең коммуникацияләр буенча җитәкчесе Антон Пушкарев әйтүенчә, бу тикшеренүләр икенче ел рәттән үткәрелә. Монда Россиянең 21 төбәгенең (шул исәптән Идел буе федераль округыннан да) сөрү җирләре ике мең гектардан алып 25 меңгә кадәр булган алдынгы 100 хуҗалык катнашкан. Шунысын да әйтергә кирәк: аларның күпчелеге – үсемлекчелек белән шөгыльләнүчеләр.

Тикшеренү нәтиҗәләре, икътисадтагы кризиска карамастан, аграр секторның менә инде икенче ел уңышка ирешүен күрсәткән. Сораштыру барышында авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең чәчү мәйданнарын арттыруы ачыкланган. Бу сорауга уңай җавапны сораштыруда катнашучыларның өчтән бере биргән. Калганнары исә мәйданнарны шул килеш калдырган, киметүчеләр булмаган. Шулай ук фермерларның 90 проценты быел үзләре җитештерә торган культураларның уңышын арттырырга ниятләвен белдергән. Моның өчен алар ашлама һәм саклык чараларын кулланырга, хуҗалыкта җитештерү процессларын белән идарә итүне ныгытырга, махсус эшкәртелгән орлыклар кулланырга планлаштыруларын әйткән. Шул ук вакытта, Антон Пушкарев әйтүенчә, фермерларның күпчелеге җитештергән товарларының бәяләрен арттырырга исәплиләр. «Димәк, көзгә бәяләр арту көтеләчәк», – ди ул.

Авыл хуҗалыгы базары конъюнктурасы институты генераль директоры Дмитрий Рылько фикеренчә, 2014 елдан Россиягә чит илдән кертелә торган товарларның күләме арткан.

– Быелның беренче кварталында Россия базарында импорт товарлары, узган ел белән чагыштырганда, 13 процентка арткан. Шул исәптән санкцияле илләрдән кертелә торган продукция дә. Безнең илгә бигрәк тә алкоголь, ит һәм сөт продукцияләре куплап кертелә башлаган, – ди ул.

Әмма, аның фикеренчә, Төркия белән мөнәсәбәтләр җайга салынса да, ул илдән Россиягә кертелә торган товарлар артуы күзәтелми.

Журналистлар белән очрашуда «Родник» (Чистай) һәм «Трио» (Алексеевск) җәмгыятьләре генераль директоры Рамил Әхмәтҗанов та бар иде.

– Россия базарындагы эш тәҗрибәм – 20 ел. Дүрт ел элек «Сингента» компаниясен Татарстанда тәкъдим итүче Илнар белән таныштым. Ул миңа Чистайда көнбагыш чәчәргә киңәш итте. Моңа кадәр әлеге культураны чәчкәнебез юк иде. Беренче елны табыш булмады. 2015 елда – 17, 5, 2016 елда – 24 центнер алдык. 2015 елда көнбагышның килограммын 26 сумга саттым. 2016 елда бәя төште – уртача 20 сумга саттык, әмма ул елны уңыш яхшы булды. Ел саен акрынлап көнбагышның чәчү мәйданнарын арттырабыз. Быел Алексеевск районында да чәчтек.

→ Ахыры 3нче биттә.

Ник качасыз, табиблар?

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫННАН

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Кичә Дәүләт Советы депутатлары сессиядә эшләп тә күрсәттеләр: ике тапкыр яртышар сәгатьлек тәнәфескә бүленеп, иртәнге уннан кичке дүртенче яртыга кадәр берсеннән-берсе әһәмиятле закон проектлары кабул иттеләр.

Линар ЗАКИРОВ

АЧ КАЛМАБЫЗ

Ниһаять, депутатлар узган елның ахырыннан эшләнеп килгән Азык-төлек иминлеге турындагы республика законының очына чыктылар. Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, бу документ ярдәмендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә уңышларын оешкан төстә җыярга һәм сатарга мөмкинлек булдырырга кирәк, дип кат-кат әйтә килде.

– Без базар шартларында Татарстанда эшләп килгән сәүдә нокталарының эшчәнлеген чикли алмыйбыз. Республикада ике арадагы хезмәттәшлекне көйләү юлларын табарга кирәк, – диде ул.

Утырышта катнашкан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов әйтүенчә, законны үтәү барышында махсус актлар төзеләчәк. «Законда теге яки бу юнәлешне тонналап, сумлап күрсәтү бик кыен булачак», – диде ул, ягъни тиешле күрсәткечләр шул махсус актларда теркәләчәк.

Депутатлар кабул иткән закон азык-төлекне тотрыклы рәвештә һәм республика халкына җитәрлек күләмдә җитештерүне күздә тота. Татарстан Президенты кул куйгач, ул үз көченә керәчәк. Сүз уңаеннан, «азык-төлек законнары» Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Ульяновск, Саратов һәм Рязань өлкәләрендә кабул ителгән инде.

ТЕШСЕЗЛӘРНЕ ТЕШЛЕ ИТИК

Татарстанның мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фондының 2017-2018 елгы бюджеты буенча үзгәрешләр хакында да әйтелде. Баксаң, фондның ел саен күпмедер күләмдә тотылмаган акчасы кала икән, ул елдан-елга күчеп бара. КПРФ фракциясе җитәкчесе Хафиз Миргалимов былтыргы соравын быел да бирде: шул калган акчаны озын-озак чират көткән өлкәннәргә медицина ярдәме күрсәтүгә тотып булмыймы соң?

Әйтергә кирәк, фонд җитәкчесе Алсу Мифтахова бу утырышта депутатларның сорауларына күтәренке рухта, хәтта, урыны белән, елмаеп җавап бирде. Иптәш Миргалимовның соравына да шундый ук рухта җавап кайтарды. Алсу Мифтахова әйтүенчә, тешне протезлау чыгымнарын төбәк бюджетлары күтәрә, ә офтальмология, ягъни күпме кешенең күз белән бәйле медицина хезмәтенә мохтаҗ булуы турында төгәл мәгълүмат юк.

«Әгәр сез безгә шундый мәгълүмат җиткерсәгез, без аны 2017-2018 елгы бюджетны планлаштырганда исәпкә алыр идек», – дип мөрәҗәгать итте Миргалимовка Мифтахова.

Фәрит Мөхәммәтшин мондый әрсезлекне тыныч кына кабул итә алмады, күрәсең... Дәүләт Советы депутаты Татарстанның мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фондына белешмә җыеп йөрергә тиешме әллә? Кайсыдыр бер депутатның соравына җавап биргәндә, Алсу Мифтахова фондта 230 чамасы кеше эшләве турында әйтте.

– Сездә чират буенча мәгълүмат юк икән, димәк, начар эшлисез, – дип кырт кисте парламент башлыгы. – Сезнең ул акчаны икенче елга күчермичә, булган проблемаларны хәл итүгә тоту мөмкинлеге бармы?

Фәрит Мөхәммәтшин, КПРФ фракциясенә шушы юнәлештә тикшерү үткәрергә тәкъдим итеп, нәтиҗәне Дәүләт Советына җиткерергә кушты.

Алсу Мифтахова чыгыш ясаганда, тагын бер нәрсә билгеле булды. Баксаң, шәхси медицина оешмалары МРТ һәм КТ юнәлешендә мәҗбүри иминиятләштерүе программасында катнаша икән.

– Дәүләт медицина учреждениесендә кайсыдыр югары технологияле җиһаз эшләмәсә, пациентлар дәүләт заказы алган шәхси клиникага җибәрелә. Квоталарны билгеләү белән республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы шөгыльләнә, – дип аңлатты Алсу Мифтахова.

Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе урынбасары Илдус Касыймов үз чыгышында әйткәнчә, 2016 елда 15 меңнән артык кеше тешләрне һәм ишетү органнарын протезлау буенча медицина ярдәмен бушлай алган. Шушы максаттан 106,2 миллион сум тотылган.

– Тик шулай да медицина ярдәмен алуга чират кимеми, ел башында 14 мең кеше теркәлгән иде, – дип, Илдус Касыймов республика бюджетын әзерләгәндә шушы мәсьәләне истә тотарга чакырды.

«Земский врач» («Авыл табибы») программасы буенча, 2012 елдан авыл җиренә кайтып эшләүче 420 медицина хезмәткәре бер миллион сумга ия булган. Әмма соңгы елларда, тиешле биш елны эшләп бетермичә, 46 табиб килешүне өздереп, авыл җиреннән киткән. Илдус Касыймов: «Һәр очракны аерым тикшерергә кирәк», – диде.

ШАУЛЫ ТАТАРСТАН

Депутатлар 2010 елда кабул ителгән тынычлык турында законга да төзәтмәләр кертергә булды. Һәркем белә торгандыр, төнге уннан иртәнге алтыга кадәр (ялларда һәм бәйрәм көннәрендә төнге уннан иртәнге тугызга кадәр) шауларга ярамый, юкса, кесәңне юкартырга мәҗбүр булачаксың.

Яңа төзәтмәләр нигезендә, мәдәни һәм спорт бәйрәмнәрендә шауларга рөхсәт ителәчәк. Депутатларны бу адымга Казанда уза торган Конфедерацияләр Кубогы да этәргәндер. Кайбер матчлар башкалабызда эш көннәрендә һәм төнгә кадәр бара бит, әгәр төзәтмәләр кертелмәгән булса, тынычлык турындагы закон үтәлмәгән булып саналыр иде. Закон проектын Рөстәм Миңнеханов якын арада ук имзаларга тиеш.

Татарстан Мөселманнары диния нәзарәтендә «Кәгазьгә тормыш бүләк ит» акциясенә нәтиҗә ясадылар. Макулатура җыю буенча хәйрия акциясе узган ел бик популяр иде, быел исә ул инде республика масштабын ялады, дип яза Диния нәзарәте сайты.

Изге айда – изге гамәл

Нәзарәттә урнашкан макулатура кабул итү пунктында оешмалардан һәм шәхси затлардан ике тонна кәгазь җыелган. Аннан кергән акчалар «Зәкят» фонды карамагындагы авыру балаларны дәвалауга юлланачак. Активистларга Диния нәзарәтенең һәм Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының истәлекле бүләкләре тапшырылды. Күз күне мөселман яшьләре активистлары «Кәгазьгә тормыш бүләк ит» акциясен дәвам итәргә ниятли.

«Рамазан – изге гамәлләр ае» акциясе кысаларында, «Зәкят» хәйрия фонды үз карамагында булучыларга һәрдаим азык-төлек җыелмалары да тарата. Кучтәнәчләрне «Зәкят» фонды генераль директоры Ирек хәзрәт Җиһаншин кулыннан йөздән артык мохтаҗ кеше алды. Араларында күп балалы гаиләләр, инвалидлар һәм кыен хәлдә калган кешеләр бар иде.

Софья Ширяева гаиләсендә барысы да – инвалидлар. Гаилә бюджетының күп өлеше даруларга китә.

– Без Диния нәзарәтенең кучтәнәчләренә бик шат, – дип сөйли Софья. – Күрсәткән игътибарыгыз һәм мөмкинлекләре чикле кешеләрне кайгыртуыгыз өчен рәхмәт сезгә.

Гөлнара Хәмидуллина ялгызы гына авыру улы Сәетне тәрбияли. Бала ДЦПдан һәм эпилепсиядән интегә.

– «Зәкят» фонды ярдәме белән, үткән ел минем улым йөри башлады! Уңышлы гына тернәкләнү курсы үткәннән соң, ул аягында нык басып тора ала, – дип тәэсирләре белән бүлеште Гөлнара.

Ирек хәзрәт Җиһаншин сүзләренчә, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр турында кайгырту – Аллаһ тарафыннан бөтенебезгә дә йөкләнгән бурыч ул.

– Көчсез һәм мохтаҗларның социаль яклауга хокуклары ислам динендә ап-ачык күрсәтелгән, – ди фонд җитәкчесе. – Инвалидлык – бары тик тән халәте генә. Ул – кешенең ныклыгын һәм түземлеген сынау. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.): «Кайгы-хәсрәтнең күләме җибәрелгән бүләк зурлыгына тиң», – дигән, ягъни Аллаһ Тәгалә үзе яраткан затларны сыный.

Тапшырылган азык-төлек җыелмаларына он, шикәр, чәй, макарон, дөге, карабодай һәм ясмык керде – барлык авырлыгы 1,5 тонна тәшкил итте. Изге Рамазан ае ахырына кадәр «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗларга, күп балалы һәм аз керемле гаиләләргә, авыруларга тагын шундый йөз кучтәнәч өләшәчәк.

Ялган акчалар кимегән

Татарстанның үзәк банкы хәбәр итүенчә, республикада ялган акчалар саны 77 процентка кимегән, дип яза TatCenter.ru. Ел башыннан Татарстанда барлыгы 153 ялган акча ачыкланган. Баксаң, ялган акчалар арасында күбесенчә биш меңлекләр очрый икән.

Шулай ук 30 данә – 1000 сумлык, биш данә – 500 сумлык, ике 100 сумлык ялган купюра табылган.

Депутатлар бүләк ясады

Кичә Татарстан Дәүләт Советы депутатлары «Игелек территориясе» хәйрия акциясенә кушылды.

«Шәһри Казан» газетасын, Шамил Яһудин ярдәме белән, Яңа Чишмә, Аксубай, Нурлат, Чистай районнарындагы картлар һәм инвалидлар интернат-йортлары, ветераннар, мохтаҗ гаиләләр алачак. Ирек Салиховның бүләге – «Шәһри Казан» газетасы – ярты ел буе Актаныш, Баулы, Ютазы, Минзәлә, районнарындагы картлар һәм инвалидлар йортларына, үсмерләр приюты, реабилитация үзәкләренә киләчәк.

Дмитрий Самаренкин «Казан» агросәнәгать паркы адресына күпләп альтернатив подписка эшләде. Марат Садыйков Казанның 7нче шәһәр хастаханәсенә күпләп килә торган альтернатив подписка рәсмиләштерде.

«Шәһри Казан» газетасына шулай ук Ринат Гайзатуллин, Светлана Захарова, Альберт Мөхәммәтшин, Артур Габделҗанов, Ринат Мистахов яздырдылар.



Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Конфедерацияләр Кубогы: нәрсә ярый, нәрсә ярамый

Шимбә көнне булачак Россия – Мексика матчына билетлар алу, җанатар паспорты тутыру гына аз. Әле стадионда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен дә үтәргә кирәк. ФИФАның стадионда хокук бозучыларга карары бер – «кара исемлек»кә керүче киләсе елга Дөнья чемпионатына эләкми.

Матч барышында ямьсез, тозсыз сүзләр белән сүгенүчеләрне стадионнан шундук куып чыгаралар. Телефоннан «туры элемтә» дә алып барырга ярамый. Ә аккредитация узганнар телефонга бер фото төшергән өчен дә «кара исемлек»кә керергә мөмкин. Фото яки видеога бары тик ФИФА аккредитациясе узган операторлар һәм фотографлар гына төшерә ала. Матч барышында стадионнан чыгып киткән кешегә бу көнне «Казан-Арена»га кире юл ябык.

Уен караган вакытта бары тик үз урыныңда гына утырырга кирәк. Футболны басып, ятып карарга ярамый. Кырга чыгу, ят әйберләр ыргыту да тыела. Хәзер Казан урамнарында Кубокка билет сатучыларны да очратып була. Бу да закон тарафыннан тыелган гамәл. Алар сезгә ялган билет сатарга мөмкин. Андый кешеләрдән ерак торыгыз.

Евгений Разумный/Ведомости

Кагыйдәләр тулырак www.shahrikazan.com сайтында

МАТЧКА ҮЗЕҢ БЕЛӘН НӘРСӘ АЛЫРГА ЯРАМЫЙ?

– Шартлаткыч, тиз янып китә торган җайланмалар (әйтик, газ баллоны);
– пычак, лезвие кебек кисә, кадый торган әйберләр;
– музыка уен кораллары;
– рулонлы яки пачкалы кәгазь;
– бронежилет;
– күләме бер савыттан арткан җиде төрле дару;
(даруын авыру кеше рус яки инглиз телендә бирелгән табиб рецепты буенча алып керә ала)
– наркотик, психотроп кулланмалар, тәмәке;
– эш кораллары;
– пыяла савытлар;
– 100 млдан да арткан сыеклык;
– термос;
– ризык, эчемлекләр;
– йорт хайваннарын;
– киңлеге 75 смдан арткан букча;
– велосипед, роликлар, скейтборд, самокат;
– 2х1,5 метрдан зуррак булган флаглар, банерлар.
– ябык килеш 25 смдан да озынрак булган зонтлар һ.б.

→ Теманың дәвамы 7нче биттә.

Күрше республика фермерлары бездән ник көнләшә?

→Ахыры. Башы 1нче биттә.

Иң мөһиме – уңыш яхшы булсын. Шулай да үзеңнең тоемлавыңа ышанырга кирәк. Аннан соң берничә төрле культура чәчсәң дә оттырмассың. Берсенең уңышы начар булган очракта да, башкасына өметләнергә була. «Сингента» компаниясе белән дә тыгыз элемтәдә торабыз, чөнки аларның орлыклары сыйфатлы, хезмәткәрләре намуслы. киңәшләре белән дә ярдәм итәләр. Шулай да бер теләгем бар: бәяләре уртачага якын булсын иде. Без бер-беребезгә бәйле бит, – диде фермер.

Татарстанның күрше төбәкләрдән субсидиягә бәйлелеге белән аерылып торуы турында да әйтте Дмитрий Рылько. Бу фикерне Рамил Әхмәтҗанов үз мисалында куәтләде.

– Минем уйлавымча, Татарстан – фермерларга субсидияләр бирү буенча Россиядә беренчеләрдән санала. Ачыктан-ачык әйткәндә, күрше республикалардагы коллегаларыбыз бездән көнләшә. Авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга каралган «60х40» дәүләт программасы бүген дә эшли. Бу безгә бик зур ярдәм. Яхшы, яңа техника үз-үзен һәрвакыт аклый. Беренчедән, ул – энергияне саклый торган техника. Икенчедән, аңа өч түгел, бер механизатор да җитә. Моннан кала, ашлама, ягулык өчен дә бик зур субсидия бирәләр. Моның өчен Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка да, министр Марат Әхмәтовка да рәхмәт, – ди ул.

Штраф күләме арта

Дәүләт Думасы җәяүлеләргә юл бирмәгән машина йөртүчеләргә административ штраф күләмен арттыру турындагы закон проектын беренче укылышта кабул иткән. Моңа кадәр ул 1,5 мең сумны тәшкил итә иде. Моннан соң 1,5 меңнән 2,5 мең сумга кадәр булачак, дип хәбәр итә «Татар-информ».

1avtourist.ru

Россия Федерациясе Министрлар Кабинетында административ җаваплылыкны көчәйтүне гамәлдәге кагыйдәләрнең нәтиҗәле булмавы белән аңлаталар. Бу кузгатылган җинаять эшләре һәм аварияләрнең саны белән раслана. Россиянең эчке эшләр министры урынбасары Игорь Зубов әйтүенчә, 2016 елда җәяүлеләр катнашындагы юл-транспорт һәлакәтләрендә 802 кешенең гомере өзелгән, 14,35 мең кеше имгәнгән.

Искәртеп үтәбез: гамәлдәге закон буенча, җәяүле юл йөрү кагыйдәләрен бозган очракта, аңа кисәтү ясала яки 500 сум күләмендә административ штраф салына.

Казан шәһәре мэриясе, Казан «Электроприбор» заводы ачык акционерлык җәмгыяте ветераны

Лошадкин Виктор Андреевич

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең туганнарының, якыннарының авыр югалту кайгысын уртаклаша.

Виктор Андреевич – шәһәребезнең хөрмәтле кешеләренең берсе иде. Ул мәдәни мирас объектларын торгызу һәм саклауга зур өлеш кертте. 2016 елда исеме Казан шәһәренең Мактау китабына кертелде. Мәрхүмнең якты истәлеге казанлылар хәтерендә озак сакланыр.

БӘХЕТЕМ БАШКАЛАСЫ

Казан шәһәр Думасында ясаган чыгыштан

Бүгенге сессиянең көн тәртибенә төп мәсьәлә итеп культура проблемалары куелу үзе генә дә башкалабызда мәдәният өлкәсенә зур игътибар бирелүе хакында сөйли. Моңа кадәр чыгыш ясаучыларны кабатламаска тырышып, мин сезнең белән үземне куандырган һәм шулай ук борчыган кайбер фикерләрем белән генә уртаклашырга телим. Чыгышымны татар телендә – дәүләт телендә ясармын. Кызганыч, бу залда Дәүләт Советындагы сыман, синхрон тәрҗемә юк. Югыйсә, чыгыш ясау өчен ике дәүләт теленә дә бертигез мөмкинлек тудыру шулай ук культура билгесе булыр иде.

Соңгы елларда Казаныбызның йөзе яктырып, шәһәребезнең Россиядә генә түгел, халыкара масштабта көннән-көн таныла баруы һәммәбезнең дә күз алдында. Без инде үзебез моңа ияләшеп, моны гадәти хәлгә саный башладык бугай. Безнең халыкта: «Үзеңнең ничек яшәвеңне беләсең килсә, күршеңнән кереп сора», – дигән гыйбарә бар. Казанга читтән килгән кунакларның көннән-көн ишәя баруы, башкалабызның туристик үзәккә әверелүе – шәһәребезгә бирелгән югары бәя дип санарга кирәк.

Әйе, без Казаныбыз белән горурланабыз, аны дөньяның иң матур шәһәре итеп күрергә телибез. Әмма, белгәнебезчә, матурлыкның, камиллекнең чиге юк. Моны башкалабыз җитәкчеләре дә яхшы беләләр һәм башкалабызны чыннан да иң гүзәл шәһәр итү өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышалар.

Безнең халыкта: «Киемеңә карап каршы алырлар, акылыңа карап озатырлар», – дигән әйтем бар. Ә шәһәрнең киеме – аның йортлары, аның биналары, урамнары, аның бизәлеше. Бу яктан караганда да, моннан 15-20 ел элеккеге күренеше белән чагыштырганда, ул күзгә күренеп яхшы якка үзгәрде. Казан шәһәре, белгәнебезчә, «Татарстан» дип аталган милли республиканың гына түгел, ә дөньяга сибелеп яшәгән дистә миллионлы татар халкының да рухи башкаласы. Әгәр без татар халкы исеме белән аталган республика башкаласында яшибез икән, кылган гамәлләребез белән дә һәрдаим моны истә тотарга тиешбез. Әмма, ни кызганыч, борынгыдан сакланып килгән һәм соңгы елларда калкып чыккан берничә дистә мәчеттән башка, шәһәребезнең архитектура йөзендә татар аһәңнәре, милли бизәкләр әлегә бик аз. Дөрес аңлагыз, мин һич кенә дә Казаныбызны тоташтан түбәтәйле, калфаклы һәм чәк-чәкле шәһәр итәргә кирәк дип санамыйм. Чөнки ул безгә үзенең татар-рус бергәлеге, культура төрлелеге белән кыйммәтле. Без Казанның Горький һәм Шаляпин, Качалов һәм Лобачевский һәм тагын йөзләгән бөек рус һәм башка милләт шәхесләре шәһәре икәнен һич тә онытмыйбыз, әмма шулай ук аның бөек Тукай һәм Фатыйх Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Ризаэддин Фәхреддин, Муса Җәлил һәм Салих Сәйдәшев каласы икәнен дә истән чыгара алмыйбыз. Казан – татар һәм рус милләтләрен, культурасын бер казанда кайнаткан, мәдәниятләр төрлелеге белән дөньяга танылган уникаль шәһәр. Шуңа күрә киләчәктә яңа проектлар төзегән вакытта архитекторларыбызга шәһәребезнең үз йөзен саклау һәм баету бурычын куярга, алардан шуны таләп итәргә кирәк дип саныйм. Бу яктан үрнәк алу өчен аларны Барселонага гына түгел, ә бәлки, Астана, Ташкент кебек милли бизәкле шәһәрләргә тәҗрибә тупларга җибәрү кирәктер?

Россиядән һәм чит илдән килгән турист бездә моңа кадәр беркайда да күрмәгән нәрсәләр күрергә өметләнә. Соңгы елларда яңартылган Иске Татар бистәсенең күзгә күренеп популярлашуы, Казан халкының һәм кунакларның яраткан урынына әверелүе шул турыда сөйли. Казаныбызның һәр урыны, һәр мәйданы, һәр тыкрыгы бай һәм мавыктыргыч тарихка һәм вакыйгаларга ия. Әмма шушы бай тарихны, матурлыкны, гүзәллекне, мәсәлән, Төркия һәм Израильдәге шикелле мавыктыргыч итеп төрле телләрдә сөйли һәм аңлата белүче экскурсоводларыбыз да әлегә бик аз.

Без шәһәребезне атаклы Казан Кремленнән башка күз алдына китерә алмыйбыз, кунакларыбызны иң беренче чиратта шунда алып барабыз. Кремль хәзер чиста, пөхтә, анда яңадан-яңа музейлар, күргәзмәләр барлыкка килә. «Кол Шәриф» мәчете белән Благовещение соборын сокланып тамаша кылганнан соң без, гадәттә, Бауман урамына төшәбез. Әмма, ни кызганыч, шәһәребез тулаем яңара, матурлана барса да, үзәк урамыбыз бүгенге көнгә кадәр, чын мәгънәсендә, Казанның горурлыгы булырлык дәрәҗәгә җитмәде әле. Франциядә гөрләтеп Сабан туе үткәреп кайтканнан соң, бәлки, Париж урамнарыннан үрнәк алып, Бауман урамының эчтәлеге дә, тышкы кыяфәте дә, милли эчтәлеге дә, хәтта атамасы да яхшы якка үзгәрер дип өметләнәбез.

«Культура» дигәч, билгеле инде, иң беренче чиратта күз алдына театрлар, музейлар, китапханәләр, концерт заллары, сәнгать уку йортлары, күргәзмәләр килеп баса. Бу яктан караганда, Казан бик тә бай рухи тормыш белән яши, дип горурланып әйтергә була. Соңгы елларда барлыкка килгән Аксенов фестивале, Константин Васильев музее, язучыларның ишегалды очрашулары, төрледән-төрле китап ярминкәләре шәһәребезнең рухи дөньясын тагын да баетып җибәрде. Кемгә – нәрсә, кәҗәгә – кәбестә дигәндәй, бу яңалыкларга милли бизәкләр өстәп, берәр атаклы татар язучысына яисә сәнгать әһеленә багышлап, «Аксенов-фест» кебек татарча «фестлар» оештырылса, шәһәрдә үткәрелә торган мәдәни чараларда татар теленә, татар музыкасына, татар сәнгатенә дә зуррак урын бирелсә, рухи дөньябыз тагын да баебрак китәр иде. Бу үзебез өчен дә, туристларны күбрәк җәлеп итү ягыннан да нәтиҗәле эш булыр иде.

Узган елны Илсур Рәис улының туган шәһәре Түбән Кама яңашәсендә Тукай исемендәге гаҗәеп гүзәл һәм уңайлы «Уку паркы» булган заманча уникаль китапханә барлыкка килде. Без, еш кына: «Хәзер халык китап укымый, китапханәләргә кеше аз йөри», – дип кабатлыйбыз. Ә менә Түбән Камадагы әлеге заман таләпләрен истә тотып яңартылган китапханәгә йөрүчеләр, китап укучылар саны бер ел эчендә биш тапкырга арткан! Бүгенге китапханә ул – китап уку өчен генә түгел, ә үзара фикер алышу, очрашу-танышу, әдәбият-сәнгать әһелләре, күренекле шәхесләр белән аралашу урыны да булырга тиеш. Бу эшне, минемчә, иң беренче чиратта, китапханәләрнең материаль-техник нигезен ныгытудан, аларны кирәкле әдәбият, вакытлы матбугат, заманча техника һәм җиһазлар белән тиешенчә тәэмин итүдән, яңа микрорайоннарда мәдәни объектлар төзүдән башларга кирәк. Белүебезчә, Казаныбызда хәзер, барыбызны да сөендереп, гаҗәеп зур һәм матур зоопарк бинасы төзелеп ята. Киләчәктә башкалабызда зоопарк бинасы кебек мәһабәт китапханәләр, концерт заллары, башка мәдәният объектлары төзелер, искеләре төзекләндерелер, маймылларга һәм зоопарк хезмәткәрләренә, зоопаркка йөрүчеләргә карата булган ихтирамлы мөнәсәбәт китапханәчеләргә һәм китап укучыларга да күрсәтелер дип ышанабыз.

Татарстаныбызны, Казаныбызны дөньяга таныту өлкәсендә мәдәни чараларыбызның әһәмияте бик зур. «Народ требует хлеба и зрелищ!» – дип борынгылар юкка әйтмәгәннәрдер бит. Аллага шөкер, хәзер күбебезнең тамагы тук, өсте бөтен. Ә шулай да әлегә ризыкларыбызның төрлелеге, табыннарыбызның миллилеге белән артык мактана алмыйбыз. Миллионлы Казаныбызда, дистәләгән япон, кытай, грузин, үзбәк, төрек, таҗик рестораннары булып та, татар һәм рус халкының туристларны җәлеп итәрлек милли ризыклары белән сыйлый торган затлы ашханәләребез әлегә бармак белән генә санарлык. Ә милли аш, милли ризык – шулай ук милли культураның бик мөһим өлеше ул.

Аннары Татарстанны, Казанны, татар халкын хәзер шулай ук милли бәйрәмебез Сабан туйларыннан башка күз алдына да китереп булмый. Әмма, ни сәбәптәндер, элек-электән, башта – җиде районның җидесендә, аннары шәһәрнең биш урынында уздырыла торган иң популяр милли бәйрәмебез соңгы елларда бер урында гына үткәрелә башлады. Мондый зур масштаблы бәйрәмнәр үткәрүне глобальләшү шаукымы белән аңлатып булса да, аның уңайсызлыклары турында да әйтергә кирәктер. Әлеге зур бәйрәмне – глобаль Сабан туен, беренчедән, бик теләсәң дә, күреп һәм колачлап бетерү мөмкин түгел, аннары аңа теләсә кем барып җитә дә керә дә алмый. Икенчедән, һәр район аерым, мөстәкыйль үткәрә торган Сабан туенда шушы тирәдә яшәүчеләр үз районнарының казанышлары, мәдәни-рухи дөньясы белән якыннан таныша алалар, бер-берсенә тагын да якынаялар. Һәр район, башка районнар белән ярышып, Сабан туена яңа төсмерләр, яңа бизәкләр өсти. Хәтта 10-15 мең кешелек Әтнә, Теләче, Кайбыч кебек район үзәкләрендә дә ел саен гөрләтеп Сабан туйлары үткәрә алганны, Казанның икешәр йөз меңле районнарын Сабантуйсыз калдыру һич кенә дә дөрес түгелдер. Россиянең татарлар яшәгән бик күп төбәкләрендә, район үзәкләрендә, хәтта Нью-Йоркта, Вашингтонда, Сан-Францискода, Монреальдә, Парижда, Берлинда, Истанбулда, Австралиядә үткәрелә торган Сабан туе татар халкының рухи башкаласы булган Казаныбызның һәр районында да үткәрелсә, бер дә артык булмас иде. Бу – минем фикерем генә түгел, бу хакта Дәүләт Советына Казан кешеләре һәм Казан кунаклары бик еш мөрәҗәгать итә. Әле күптән түгел генә кабул ителгән «Матди булмаган мәдәни ядкарьләр турында»гы законыбыз милли бәйрәмнәребезне, гореф-гадәтләребезне һәм йолаларыбызны саклау һәм үстерү өчен өстәмә мөмкинлек бирер дип уйлыйбыз.

Заманында без композитор Илгиз Закиров белән, Казаныбызга багышлап, «Бәхетем башкаласы» дигән җыр язган идек. Ул җырны без генә түгел, киләсе буыннар да яратып җырласын, Казан каласы безгә генә түгел, алар өчен дә «бәхет башкаласы»на әверелсен иде.

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре,
Дәүләт Советының мәгариф,
мәдәният, фән һәм
милли мәсьәләләр
комитеты рәисе.

Юрист булам дисәң

АБИТУРИЕНТ – 2017


Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Элек-электән юрист һөнәре дан-шөһрәт, зур акчалар хакында искәрткән. Ә бүген юридик белемнең дәрәҗәсе ни хәлдә? Бу хакта Бөтенроссия дәүләт юстиция университетының Казан филиалы директоры Галина КУЛЕШОВА белән сөйләштек.

Алисә САБИРОВА

– Галина Петровна, сер түгел, бүген дәүләт техник белгечлекләргә өстенлек бирә. Мәгариф системасында кыйммәтләр үзгәргән чорда, юридик белем алу актуальме?

– Юридик белем һәрвакыт популяр булды, ул шулай булып калачак та. 1990-2000 елларда дәүләтнеке булмаган уку йортлары «капчыклап» юристлык дипломы таратты. Ул чорда юристларның кыйммәте-дәрәҗәсе төшү дә бәлки шуннандыр. Хәзер исә абитуриентлар дәүләт уку йортларын сайлый. Аңа диплом гына түгел, инде гамәлдә кулланып була торган сыйфатлы белем дә кирәк. Юстиция университетының 45 еллык тарихы бар, шуңа да бу өлкәдә системалы белем бирәбез дип ышанып әйтә алам.

– Абитуриент укырга кергәнче кайда эшләячәген, ничә сум хезмәт хакы аласын алдан уйлап куя. Сездә укып чыгучылар нинди өлкәләрдә эшли? Яхшы юристның хезмәт хакы күпме?

– Статистика күрсәткән соңгы мәгълүматлар буенча, бездә укып чыгучыларның 70 проценты эшкә урнашып бара. Алар сак органнарында да, дәүләт структураларында да үз юнәлеше буенча хезмәт итә. Яхшы юристның хезмәт хакы да яхшы. Моңа әле социаль пакет та өстәлә.

– 2016 елда сез зурлап «өй туе» уткәрдегез. Яңа бинага күчену уку процессына нинди үзгәрешләр кертте?

– Моңа кадәр Карбышев урамындагы элеккеге балалар бакчасы бинасында укыта идек. Хәзер инде бөтенләй башка дәрәҗә. Яңа бинага күчкәч, мондагы мөмкинлекләрне күреп, студентларның күзләре шар булды. Көн саен диярлек төрле чаралар оештыра башладылар. Аларның укыйсы, безнең укытасы килде. Әлеге бинаны төзекләндерүгә һәм җиһазландыруга республиканың 120 миллион сум акчасы киткән. Бу – безнең уку йортының дәрәҗәсен күтәрү максатыннан башкарылган эш. Әлегә тулай торагыбыз юк. Аңа карамастан, студентларның 70 проценты – читтән килеп укучылар. Быелдан без «Милли куркынычсызлыкның хокукый тәэмин ителеше», «Юриспруденция» юнәлешләре буенча магистратурага, «Хокук һәм социаль тәэмин ителеш», «Хокук һәм суд идарәсе» юнәлешләре буенча IX сыйныф укучыларын кабул итәбез. Соңгысы уку йорты каршындагы көллият буларак эшләячәк. Көллияткә бары аттестат нәтиҗәсе буенча гына укырга керәсең. Ә урта белем үзләштергәннән соң, БДИ бирмичә, югары белем алуны бездә дәвам итеп була. XI сыйныфтан соң көллияткә укырга керергә теләүчеләр рус теле, тарих, җәмгыять белеме буенча өстәмә имтиханнар тапшыра. Институтка исә БДИ нәтиҗәләре буенча кабул итәбез.

– Республикада юридик белем бирүчеләр күп, сезнең үзенчәлек нәрсәдә?

– Без – ведомство вузы. Россия Федерациясенең Юстиция министрлыгына карыйбыз. Казанда андый югары уку йортлары сирәк.

– Ел саен Державин укуларын оештырасыз. Студентларга ул нәрсә бирә?

– Безнең университет зур – Россия буенча аның тагын 15 филиалы бар. Географиябез Иркутск, Хабаровск, Петрозаводск, Санкт-Петербург, Саранск, Тула, Калуга, Барнаул, Екатеринбург шәһәрләрен эченә ала. Бу филиалларның барысында да студентлар фәнни эш белән шөгыльләнә. Безнең филиаллар арасында үз бәйгеләребез дә шактый. Ә менә Державин укулары филиалларны гына түгел, юридик белем бирә торган барлык уку йортларын берләштерә. Студентлар фән белгечләре белән бертигез дәрәҗәдә докладлар әзерли, төрле актуаль темаларга чыгышлар ясый. Бу, әлбәттә, студент өчен зур тәҗрибә. Укучылар хокук актлары, законнар, фәнни әдәбият белән эшләргә өйрәнә. Быел Державин укулары сентябрьдә узачак.

– Дүрт ел эчендә студент, укудан тыш, тагын кай яклап камилләшергә тиеш?

– Юрист бер үк вакытта оста оратор да, хокук документлары белән эшли белергә дә, логик фикер йөртә белүче дә, зиһенле дә булырга тиеш.

– Сезнең үз юридик клиникагыз да бар. Аның турында да тулырак беләсе килә.

– Бирелә без шәһәр халкына бушлай юридик ярдәм күрсәтәбез. Студентлар, укытучылар гражданлык хокукы юнәлешендә халыкка төрле киңәшләр бирә. Гадәттә, кешеләрне торак-коммуналь хуҗалыгы, юл-транспорт һәлакәте, кулланучылар хокукын яклау кебек мәсьәләләр борчый. Практиканы II курстан үтә башлыйлар. Адресыбызны үзгәртү сәбәпле, клиентлар агымы азайды. Теләгән һәр кеше безгә яңа адрес буенча мөрәҗәгать итә ала: Әмирхан урамы, 12 а, 101нче кабинет.

– Студентларга матди ярдәм бармы?

– Кызганыч, быел безгә республика тарафыннан бюджет урыннары бирелмәде, ләкин төп вузыбыз укучылары II курстан бюджет урыннарына үзе күчерә ала. Узган ел 15 бюджет урыны биргәннәр иде. Моның өчен студент яхшы укырга, уку йортының фәнни һәм иҗади тормышында катнашырга тиеш. Бөтен буш бюджет урыннары турында мәгълүмат сайтка эленеп бара. Студентларыбыз шулай ук Татарстан Президенты стипендиясе, Державин исемендәге стипендиягә дәгъва кыла ала. Дәүләт вузы буларак, социаль стипендия дә бар.

– Студент иҗади яктан яки спортта үзен күрсәтә алсын өчен нинди мөмкинлекләр бар?

– Быел безнең укучылар өчен парламент дебатлары клубы ачылды. Бирелә филиал укучылары да, Казан вузлары да катнашты. Бездә «Сәламәт яшәү рәвеше» дигән программа эшли. Аның буенча һәр студент факультатив буларак берәр спорт секциясен сайларга тиеш. Хәзер бездә волейбол, бокс юнәлешләре актив эшли. Киләсе елдан көрәш секциясен ачарга уйлыйбыз. Тренажер залыбыз бар. Быел студентлар аеруча да актив булды. Беренче тапкыр «Студентлар язы» фестивалендә катнаштык. Җыр, бию, театр миниатюрасы кебек түгәрәкләр дә эшли.

УКУ БӘЯСЕ

Көндезге уку бүлеге – **85 000 сум;**
Читтән торып уку – **60 000 сум;**
Көллият – **45 000 сум.**

ЮНӘЛЕШЛӘР

– Юриспруденция;
– Милли куркынычсызлыкның хокукый тәэмин ителеше;
– Социаль тәэмин ителеш хокукы һәм оештырылуы;
– Хокук һәм суд идарәсе.

УРТАЧА БДИ БАЛЛЫ

Рус теле – **39 балл;**
Тарих – **36 балл;**
Җәмгыять белеме – **46 балл.**

Татарстанда юристларның уртача хезмәт хакы – **25 000-75 000 сум.**

Ике метрлы балык тотарга рөхсәт

ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ

Татарстандагы зур елгаларда балыкларның уылдык чәчү чоры тәмамланды.

Һәвәскәр балыкчыларга – 25 апрельдән 10 июньгә кадәр, ә балык промыселларына 15 апрельдән 15 июньгә кадәр чикләүләр кертелгән иде.

– Республикада «Уылдык» операциясе һәр язда игълан ителә. Балыкларның уылдык чәчү чорында елгаларга моторлы көймәләрдә керү, сәнәгать куләмнәрендә балык тоту катгый тыела. Һәвәскәр балыкчыларга, балыкларның уылдык чәчү чорында да, ярдан кармак белән балык тоту рөхсәт, ләкин кармак җебендә энәләр ике берәмлектән артырга тиеш түгел, – диде «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә республиканың Тереклек дөньясы объектларын саклау һәм файдалану буенча идарәсенең бүлек җитәкчесе Радик Мутахаров.

Балыкларның уылдык чәчү чорында көймәдә берничә кармак яки ятьмә белән балык тоткан кешеләргә ике мең сумнан биш мең сумга кадәр штраф салына. Әгәр ятьмә белән берничә центнер балык тотсаң, 300 мең сумнан 500 мең сумга кадәр штраф һәм хәтта ике елга кадәр иректән мәхрүм калу яный.

Быелгы язда 1632 административ штраф беркетмәсе тутырылган, 62 җинаять эше кузгатылган, 3028 берәмлек ятьмә конфискацияләнгән. Бу ятьмәләрнең гомум озынлыгы – 400 километр, Казаннан Түбән Новгородка кадәр сузарлык.

Җәйге чорда көймәләрдә Идел, Чулман, Нократ елгаларының уртасына кадәр кереп, кармак белән балык тотарга рөхсәт. Һәвәскәр балыкчыларга ятьмә белән балык тоту, гомумән, тыела. Шулай ук суднолар йөреше юлына туктарга ярамый.

– Әгәр, бәхет елмаеп, кемдер кармак белән ике метрлы җаен балыгы тота икән, бу – аныкы. Чөгә балыгын тоту тыела, – дип искәртте Радик Мутахаров. – Кармакка эләккән балык балаларын да кире суга җибәрергә кирәк. Мәсәлән, кечкенә җаен балыгы эләгә икән, суга кире җибәрик, үссен.

Дамир БӘДРИЕВ.


otmaster.ru

ХӘТЕР

ТАТАР МУЗЫКАНТЫ ТӨРКИЯДӘ КАЛДЫ...

Апрель азагында Төркиягә барган җирендә музыкант Арион Рәхмәтуллин вафат булды. Ул җир куенына да шунда ук тапшырылды. Төркиягә алар музыкант Сәйдәш Гарифуллин белән бергә баралар. Арион Рәхмәтуллин Сәйдәш әфәнденең кулында диярлек җан бирә.

Арион әфәнде инде озак еллар җәйге курорт сезонында Төркиядә яши һәм эшли иде. Аның анда йорты да бар. Эстрадада эшләгән чорымда, 90нчы еллар башында дип хәтерлим, мине дә бер сезон бэк-вокалда эшләргә чакырганы булды. Антальяның купшы бер отелендә арт-директор һәм музыкант булып эшли, музыкаль һәм күңел ачу чаралары уздыра иде. Ул елларда әле Төркиягә югары даирә кешеләре генә йөри ала иде. Президентлар гына... Аңа мине Төркиягә чакырырга Клара апа Хәйретдинова тәкъдим иткән иде. Арион әфәнде белән телефоннан сөйләшү истә калган. «Сез нинди телләрдә җырлыйсыз?» – ди ул. «Татарча», – дим. «Тагын?» – ди. «Русча «Самарские страдания»не җырлый алам», – дим, шаярып. «Безнең отельдә күбрәк немецлар ял итә. Немецча беләсезме?» «Беләм ике сүз», – дим. Бер күрмәгән кеше белән бу кадәр кылтаеп сөйләшү килешмәсә дә, шаяруны дәвам итәм. Хәер, башка чара юк бит, татарча җырлап, немецны шаккатырып булмаска охшап тора. «Нинди сүзләр ул?» – ди Арион. «Ауфидерзейн белән хенде хох», – дим. Трубкада Арионның кычкырып көлүе яңгырый. «Все, Вы мне подходите. У вас все в порядке с чувством юмора, всему остальному я вас научу», – ди ул, көлеп туктагач.

«Подходите»сы – хак та бит, минем чит ил паспорты да, ул елларның фәкыйрьлеге сәбәпле, «кесә акчасы» да юк. Бар булганы – шул юмор хисе дә «Ах, мой милый Августин» җырын оригиналда өйрәнү теләге генә.

Опера театры каршында очрашып сөйләшәбез. «Ярый, юлыгызга мин үзем түләрмен. Паспорт ясатыгыз, бер атнадан китәргә», – ди Арион... Озын сүзнең кыскасы... барып булмады. Паспорт та ясатып өлгермәдем, җитмәсә кайбер дусларым да минем анда озак тора алмаячагымны аңлаттылар. Баянчы Рамил Баһаутдинов белән бик дус идек (күптән мәрхүм инде), ул да: «Барма, Зимфира, берәр карт төреккә арзанга сатарлар үзеңне», – дип «куркытты».

Арион белән танышлыгымның бар тарихы шул, ләкин исемен телгә алганда: «Мин аны беләм бит» диярлек булды.

* * *

Дустын Төркиядә җир куенына тапшырган аккордеончы Сәйдәш Гарифуллин белән Арион Рәхмәтуллинны искә алып сөйләшеп утырдык.

– Сәйдәш абый, Арион белән дуслыгыгыз кайчан башланды?

– 1973 елны Франциягә тарихи гастроль булды. Татарстан комсомолы җитәкчелегендәге сәяхәт иде ул.

Ул заманда КХТИда «Ровестники» дигән төркем бар иде. Җитәкчесе – Арион, ә Опера театрының хәзерге директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов анда синтезаторда уйный иде. Барлыгы биш кешелек төркем иде инде ул. Ул заманнарда ТАССР мәдәният министрының беренче урынбасары Лилия Нарбекова иде, Франциягә киткәнче, ул Арион белән әңгәмә уздырган: «Син яшь кеше, чит илдә калырга уйлама», – дип. Арионның гел озын итеп йөртә торган чәчен дә бераз кистерттеләр ул чакта.

Минем филармониядә эстрада бүлеге җитәкчесе булган вакыт. Сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов үзенә чакырды да, Франциягә делегация бара, аларга аккордеончы кирәк, диде. Франция буйлап ун көнлек гастрольләр булды.

– Юлда кеше беленә инде: холкы, фигыле...

– Холкы яхшы иде аның. Ул үзе Башкортстанның Мәләвез шәһәрендә туып-үскән. Әнисе – оста биюче. Мәскәүләрдә чыгыш ясаганы булган. Улына да Пушкин герое исемен кушкан – Арион дип. Кыяфәте буенча әллә нинди халыкларга охшаган иде ул. Аны япон дип тә, кытай, кореялы, вьетнам, башкорт дип тә атап булыр иде.

Интеллигент иде, үзен кешеләрдән югары кую, аерым таләпләре булмады, адекват, нормаль кеше. Мин җитәкче дип, беркайчан өйрәтмәде, кисәтмәде, музыкант буларак, безнең барыбызга да ышанды. Ә бит ул чакта инде ике ел София Ротару төркемендә эшләп кайткан иде.

– Ул төркемгә ничек эләкте икән?

– Казан консерваториясендә ике ярым укып чыкты. Берсе – Гамма Скупинский, Черновцыдан. Ул хәзер Голливудта эшли, фильмнар өчен көйләр яза. Икенчесе – Анатолий Коган. Арион алар белән ничек танышкандыр, белмим, алар гел хезмәттәшлектә булдылар. Алар белән тагын Володя Гурьянов дигән музыкант бар иде. Алар дүртесе «Червона Рута» дигән ансамбль төзи һәм Черновцы филармониясенә китеп, эшкә урнашалар. София Ротаруны аларга яшь солистка итеп тәкъдим итәләр. Шул ук дәвердә Арион ничектер Казан консерваториясендә дә укыган. Зилә Сөнгатуллина, Вафирә Гыйззәтуллиналар белән бер вакытта укыган ул.

– Консерваториягә кереп, музыкаль белемне кайда, ничек алган икән?

– Сугыш вакытында Ленинградның Хәрби дирижерлар мәктәп-интернаты Уфада эшли. Арион ун ел шунда укый. Фатыйх исемле дусты белән Казан консерваториясенә берсүзсез алалар аларны. Арион әле дүрт ел Натан Рахлин оркестрында да эшли, чөнки аның төп белгечлеге – гобойчы. Симфоник оркестрда, Рахлинда эшләү бик зур нәрсә инде ул. Ротаруда эшләүнең исеме зур, ә менә Рахлинда эшләү – дәрәҗә.

– Татар музыкасына мөнәсәбәте ничек иде аның?

– Менә бер тарих. Минем әнидән генә ишеткән җыр бар иде, Тукай сүзләренә ул – «Сандугач һәм Фатыйма» дип атала. Аны белүчеләр юк диярлек. Илһам абыйдан да, Рафаэль Ильясовтан да сораганым булды, ишеткәнебез юк, диделәр. Бөтенләй онытылганчы, радиога яздырырга кирәк бит инде бу җырны дип уйладым да, музыкант егетләр белән сөйләшеп, арада Арион да бар, инструменталь вариантны язар өчен, радиога килдек. Репетициясез язылдык. Арион ноталарны язып бирде, аның язуы бик матур каллиграфик язу иде. Арионны шулай да кисәттем – миңа Чикагоча уйнарга кирәкми, мин әйтәм. «А что, по деревенски что ли надо?» – ди. Нәкъ шулай, минәйтәм. Шундук уйнап бирде, бер сәгатьтә без ике көй яздык.

Арионны чын татар музыканты дип атап булмый иде, ул Битлз белән җенләнгән, көнбатыш музыкасына юнәлгән кеше иде. Ләкин Илһам Шакиров белән эшләп алу аны бераз милләткә якынайткандыр дим. Илһамда эшли башлагач, бик көчле генә төркем җыйды ул, яхшы гына эшләделәр. Ренат Ибраһимов төркемендә ун еллап эшләде, музыка җитәкчесе булды. Соңгы елларда «Җырлыйк әле!» тапшыруында уйнады. Шунда үзе моңарчы уйнамаган да, мөгаен, ишетмәгән дә көйләрне, Сара Садыйкова җырларын, халык җырларын ишетеп: «Смотри, какие шедевры оказывается есть в татарской музыке», – дип таң калып сөйләгәне булды. Арион күпме дөнья гизгән, күпме күргән, шаккатырып булмас кебек, ә татар көен ишетеп, соң булса да шаккаткан. Мин аңа күптән түгел «100 халык көе» дигән җыентык бирдем. Ул аны Гамма Скупинскийга, Голливудка җибәрергә тиеш иде. Татар көйләрен чын-чынлап соңгы елларында тоя, санлый башлады ул.

– Сез гаилә дуслары булып яшәдегезме?

– Арион белән якын, көн дә аралашкан дуслар идек дип булмый. Эш буенча аралаша идек. Аның хатыны Надежда да музыкант, скрипкачы. Арионның беренче хатыны Алмаз Монасыйповның кызы иде. Ул хатыны да музыкант, әлеге никахтан туган кызы да музыкант, пианистка.

– Төркиягә яшәргә ничек чыгып китте икән ул?

– Филармониядә ул заманнарда Вадим Усманов җитәкләгән «Орфей» ансамбле бар иде. Шул ансамбльнең солисты Гүзәл Әхмәтшина Голландия кешесенә кияүгә чыгып, шунда китте. Иренең төрек дусты бар, ә аның отельләре күп икән. Шул отельләргә музыкантлар кирәк иде. Арион мине чакырды да, без иң беренче музыкантлар булып, шунда киттек. 1990 еллар башы. Өч ай эшләп кайттык анда.

Арионга анда бик ошады, Антальядан ерак түгел генә йорт та сатып алды, ел саен бара башлады.

Ә соңгы елларда ул инде күбрәк Казанда, соңрак Мәскәүдә булды. Быел апрель башында: «ӘйдәТөркиягә барып эшләп кайтабыз», – дип шалтыратты. Мин Мәскәүгә поезд белән бардым да, аның машинасына утырып, Кавказ, Грузия аша Төркиягә киттек. Юл буе рульдә, юл буе кызык хәлләрне искә алып бардык. Май башында эшли башларга тиеш идек.

Арионның йортына барып җиттек. Беркөнне Арион ашый алмый, укшый башлады. Урынына илтеп салмакчы булам – атламый, суламый. Аңсыз дип уйладым инде. Күршеләре белән «Ашыгыч ярдәм» чакырдык. Килделәр. «Үлмеш», – диделәр. Табиблар: «Инсульт та, инфаркт та, тромб та булырга мөмкин», – диделәр. Төгәл сәбәбе төрекләрдә ике айдан гына билгеле буласы.

Арионны Төркиядә мөселман зиратында җирләдек. Үзе дә бервакыт Төркиядә күмелү турында телгә алган булган, ахрысы. Гаиләсе дә каршы килмәде. Бирегә алып кайтып күмү күп вакыт, зур чыгымнар сорар иде. Төркиядә күмгән өчен бер тиен дә түлисе түгел. Барысын да оештыручы махсус кешеләр бар, җиренә җиткереп, йоласын үтәп башкаралар. Аның анда йорты калды, күршеләре, төрек дуслары күп. Кабере ташландык тормас.

Әңгәмәдәш – **Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.**

РОНАЛДУГА каршы тора алмадык

КОНФЕДЕРАЦИЯЛӘР КУБОГЫ

Россия – Португалия матчы җанатарлар өчен дә, футболчылар өчен дә зур бәрелеш иде. Күпләр уенга кадәр үк ил җыелмасына кул селтәде. Янәсе, кая безгә Роналду белән көч сынашырга?! Чыннан да Криштиану матчның сигезенче минутында беренче һәм бердәнбер голын кертте. Россиялеләр исә хисапны тигезли алмадылар. Нәтиҗәдә – 0:1.

rg.ru

Португалиялеләр Россия сагына көчле футболчылар батальоны туплаган иде. Мексика белән булган уеннан соң, тренерлары Фернанду Сантуш дүрт спортчыны алмаштырган. Роналдуның голы безнекеләрнең ышанычын какшатты. Беренче таймда ил җыелмасының уңышсыз паслары күп булды. Капкачы Игорь Акинфеев булмаса, бәлки бу уен да, 2004 елдагы кебек, Россия капкасына кертелгән 7 гол белән тәмамланыр иде. Һәрхәлдә, беренче таймда Акинфеев үзен дөнья дәрәҗәсендәге капкачы кебек тотты. Виктор Васин да кирәкле вакытта кирәкле урында була белде. Командаһы ул бернична тапкыр коткарды.

Безнекеләр тизлек ягыннан да калышты. Россия футболчысы капкага барып җиткәнче, аны инде бернична көндәш сагалый торды. Уен барышында Федор Смоловның бернична һөҗүме истә калды. Ләкин кыска вакыт эчендә җыела алмавы аркасында, туп капкага кермәде. Португалия уенчылары Пепе белән Бруну Алвешка эш аз булды, туп аларга кадәр барып та җитмәде диярлек.

Икенче таймда безнекеләр тәмам уяндылар. Көчле, әкайбер вакытта кырыс һөҗүмнәр ясый башлады. Максат ничек тә уенны 1:1 белән тәгәлләү иде. Нәтиҗәдә Португалия җыелмасы спортчысы – Герреро хастаханәгә китте. Россия җыелмасының өч уенчысы Денис Глушаков, Георгий Джикия, Александр Самедов «сары карточка» алды.

Уен буе яңгыр сибәләсә дә, трибуналардагыларны бу сүрелдермәде. Анда «кызу» иде. Туп көндәш капкасына таба бара башласа, бигрәк тә... Соңыннан Криштиану Роналду, җанатарларның бу кыланмышы безгә яхшы уйнарга комачаулады, дигән.

Роналду голы буенча гаепне Акинфеев тулысынча үз өстенә алган.

– Роналду тубы кертелүгә гаепнең 80 проценты – минем өстә, – дигән ул.

Сүз уңаеннан, капкачы бу юлы ил җыелмасы өчен йөзенче матчын уйнады. Россия тренеры Станислав Черчесов сүзләренчә, әлеге уенда команда үз алдына куйган максат-бурычларны тулысынча үтәгән.

Шимбә көнне Россияне чираттагы көндәше – Мексика уенчылары көтә. Матч 18.00 сәгатьтә башлана. Бу безнекеләр өчен хәлиткеч уен булачак. Аның нәтиҗәсе буенча, ярымфиналга чыгучылар билгеле булачак.

Казанда Месси рәсеме дә булачак

Кичә Казан мэры Илсур Метшин Конфедерацияләр Кубогын яктыртучы халыкара журналистлар белән очрашты. Очрашу вакытында бирелгән иң кызыклы сорау-җавапларны сезгә дә тәкъдим итәбез.

– Россия җыелмасы Португалиягә оттырды. Сез футболны якыннан белгән кеше буларак, россиялеләрнең ярымфиналга чыгу мөмкинлеген ничек бәялисез?

– Кичә җиңәргә теләк тә, мөмкинлекләр дә бар иде. 24 июнь көнне булачак матчта казанлылар Россия җыелмасына тагын да ныграк көч бирер, бу энергия аларга ярымфиналга чыгарга ярдәм итәр дип уйлыйм.

– Португалия командасы җиңсә, Роналду тагын Казанга кайтачак, бөтен дөньяның күзе бездә булачак. Бу чарага нинди дер әзерлек барамы?

– Без бит Роналду килә дип махсус әзерләнмәдек. Рәсемгә килгәндә, бу минем Университетадан калган гадәт. Беренче карашка гади, күзгә күренмәгән әйберләр түбәгә менгәч күренә башлый. Мин Роналду яши торган бүлмәгә кердем. Карасам, аста ямьсез гараж, каршыда совет чорыннан калган өч катлы йорт тора. Нәрсә дә булса уйлап торырга вакыт юк иде, бинаны да сүтеп булмый. Менә шунда Роналдуның бер күзен кысып төшкән сурәте башка килде. Хәзер кешеләр монда Роналду үзе тукталганын белеп торачак.

– Дөнья чемпионатында сездә Аргентина җыелмасы уйнаса, Казанда Лионель Месси рәсеме дә булачакмы?

– Сүз бирәм. Казанда ун меңләп зур бина бар. Дөнья чемпионатында катнашкан һәр футболист өчен урын җитә бездә.

– Кубок әлегә тыныч бара, ләкин шул ук Англия җыелмасы килсә, шулай ук тәртип сагында кала алырсызмы? Марсельдәге тәртипсезлекләр башланмасмы?

– Казан теләсә кайсы каршылыкларга да әзер. Без моның өчен барысын да эшләдек. Англия җанатарлары белән тыныш инде без – «Ливерпуль»ны кабул иткән бар.

– Роналду белән очраштыгыз, ул сездә нинди тәэсир калдырды?

– Йолдыз никадәр якты рак яна – шуның кадәр ул гадирәк икән. Роналду әлек миңа буй җитмәс кебек иде, ә шулкадәр гади, ачык, киң күңелле кеше булып чыкты. Ул миңа бик ошады.

– Бәлки Роналдуны үзебездә генә калдырырсыз?

– Үз Роналдуларыбызны тәрбияләсәк, яхшырак. Без беренче булып галәмгә очкан, футбол уйнарга гына өйрәтербез.

– Конфедерацияләр Кубогы тамашачының «Рубин» белән кызыксынуын арттырырмы?

– Яхшы әйбер тамашачыны һәрвакыт җәлеп итә. Хәзер Корбан Бердыев кайтты, бу да тамашачыда кызыксыну уятачак. Кызганыч, узган ел без тамашачыны зур җиңүләр белән сөендерә алмадык. Казан җанатарлары яхшы футболны сагынган инде.

КЫЗЫК ТА, КЫЗГАНЫЧ ТА

⚽ Россия җыелмасының иң кыйммәтле футболчысы – Алан Дзагоев. Аның бәясе – 15 миллион евро. Бәя буенча икенче урында капкачы Игорь Акинфеев тора (14 миллион евро). Өченче урында – Олег Шатов. Бәясе – 12 миллион евро.

⚽ Матч барышында җанатарның йөрәк тибеше 160ка күтәрелергә мөмкин. Бу – уйнаган вакытта футболистның йөрәк тибешенә тиң.

⚽ Әфганстан белән Гренландиядә, рәсми рәвештә, футбол уйнарга ярамый.

⚽ XIX гасырда яшәгән футбол белгече тарихта беренче тапкыр җитди кагыйдә бозган командага 11 метр ераклыктан капкага туп тибәргә тәкъдим иткән. Аның исеме – Джон Пенальти. Шул вакыттан әлеге штрафны «пенальти» дип йөртәләр.

⚽ 1998 елда Конго Республикасында матч барган вакытта, футбол кырын яшен суга. Кунак команданың барлык 11 уенчысы да үлә, ә кабул итүче команда уенчыларына берни дә булмый.

⚽ Тарихта иң зур исәп – 149:0 булган. Мадагаскарның «Stade Olympique l'Emyrne» командасы, хөкемдарның гадел булмаган карарына үпкәләп, үз капкаларына туп кертә башлый. Матч ахырына кадәр үзләренә 149 гол кертә алар.

⚽ КНДРда, футбол ярышларында җиңелгән өчен, концлагерьга җибәргәннәр. 1966 елда Дөнья чемпионатында ярымфиналда җиңелгән өчен, бер һөҗүм итүчедән кала барлык футболчыларны да лагерьга җибәргәннәр. 2011 елда ил җитәкчеләре карары буенча, җыелма тренеры Кима Чена Хуна тәрмәгә эләккән. Ул вакытта җыелма 0:7 исәбе белән оттыра.

Владимир ЛЕОНОВ: «КУБОККА РОССИЯ ШУЛКАДӘР ӘЗЕР БУЛЫР ДИП КӨТМӘГӘННӘР»



Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов сүзләренчә, 2018 елдагы Дөнья чемпионаты Конфедерацияләр Кубогы кебек булачак, бары тик форматы гына ике тапкыр зуррак.

– Конфедерацияләр Кубогы чемпионат алдыннан репетиция генә. Киләсе елга стадионда, оештыру эшләрендә бернична вак-төяк әйберне генә үзгәртәсе була. ФИФА Конфедерацияләр Кубогына Россия шулкадәр әзер булыр дип көтмәгән дә, – ди Владимир Леонов.

Хәзер билет белән кызыксынучылар да арткан. Ярымфиналга 3000 билет сатылган инде. Министр сүзләренчә, 28 июнь көнне кемнәр уйнаячагы билгеле булгач, футбол карарга теләүчеләрнең саны әле тагын артачак.

– Бу юлы стадион тулыр дип уйлыйм. Зур чиратлар булмасын өчен, матчка алданрак килегез. Без kzn2018.com сайтында стадионга алырга ярамаган әйберләрнең исемлеген язып элдек. Кергәндә тоткарламас өчен, үзегез белән зур кулчатыр, профессиональ фотоаппарат алмагыз, – ди Владимир Леонов.

Матчка кадәр Fan-ID җанатар паспортын булдырмаганнар өчен «Казан-Арена» каршында махсус чатырлар эшләячәк.

Актриса Екатерина СКУЛКИНА: «РОССИЯ ҖЫЕЛМАСЫНА КАРШЫ БЕР РОНАЛДУ ГЫНА УЙНАСА ДА СҮЗЕМ ЮК»

2018 елда булачак Футбол буенча дөнья чемпионатының Казан илчесе «Comedy Woman» резиденты Екатерина Скулкина да матч карарга безгә килә.

24 июнь көнне булачак Россия – Мексика уенында ул ил җыелмасы өчен көч бирәчәк.

– Финалга кем чыгуы мөһим түгел, иң мөһиме – шуларның берсе Россия булсын. Бәлки Германия белән Роналдуның да чыгуын телимдер. Россия җыелмасына каршы бер Роналду гына уйнаса да сүзем юк. Бер-бер артлы өч туп керткәнен күргәннән соң ошый башлады ул миңа. Роналду бик мөлаем икән, – ди «Comedy Woman»ның иң яхшы футбол белгече Екатерина Скулкина.

Алисә САБИРОВА әзерләде.

СӘЛАМӘТЛЕК

Иң зур җиңү – сәламәт баланың елмаюы

Республика балалар клиник хастаханәсе табиблары ел саен матбугат хезмәткәрләре белән очраша. Хастаханә белән болай да һәрвакыт тыгыз элемтәдә эшлибез, ә бу көнне журналистларга «тыелган» бүлмәләргә дә ишекләр ачыла. «ШК» журналистлары да хастаханәнең операцияләр ясау һәм реанимация бүлекләрендә булып кайтты.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Эльвира МОЗАФФАР

Ни өчендер бу клиника, авыруларны дәвалый торган медицина учреждениесеннән бигрәк, сабыйлар йорты буларак күз алдына килеп баса. Хастаханә ишегалдында елмайган балаларны күреп, башкача уйлап та булмый. Баксаң, аларның күбесе инде савыккан, өйләренә ашыга. Ә хастаханә эчендә балаларны елмайту өчен күпме көч баш карыла… Анда – аерым дөнья.

«ОПЕРАЦИЯНЕ «БИСМИЛЛА» ӘЙТЕП БАШЛЫЙБЫЗ»

Республика балалар клиник хастаханәсендә барлыгы 11 операция залы бар. Яңа туган сабыйдан алып 18 яшькәчә төрле диагнозлы балаларны китерәләр. Елына 12 меңнән артык операция башкарыла. Бу – атнасына уртача 250 операция дигән сүз.

– 18 яшемнән бирле медицина өлкәсендә эшлим. Һәр операцияне уң кулдан, «бисмилла» әйтеп башлыйбыз. Авырулар, ата-аналар, хезмәткәрләрнең үзләре өчен дә биредә барлык шартлар да тудырылган. Гыйбадәтханәләр дә бар, – ди 28 ел шәфкать туташы булып эшләүче Миләүшә Халикова.

Операция блогы бүлегенең җитәкчесе, балалар хирургы Рифат Идрисов әйтүенчә, хастаханәдәге заманча югары технологияле җиһазлар барлык төр операцияне дә ясарга мөмкинлек бирә, табиблар чит илләрдә тәҗрибә туплый, һәркем – үз эшенең остасы.

– Көнәнә – 24 сәгать, елына – 365 көн. Безнең эш сәгатебез әнә шундый. Тәүлек буе балаларга югары сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтергә тырышабыз. Офтальмология, йөрәк-кан тамырлары авырулары, баш һәм арка миенә, урология буенча катлаулы операцияләр башкарыла. Татарстанның төрле районнарыннан, шул исәптән чит төбәкләрдән дәваланырга килүчеләр дә җитәрлек. Баш табиб Рафаэль Шәвәлиев – идеяләр тәкъдим итүче, ә без шул тәкъдимнәрне тормышка ашырабыз, – ди табиб.

Операциядән соң балалар махсус уяну (пробуждение) бүлмәсенә озатыла. Алар операциядән соң күзләрен ачканда уңайлы булсын өчен барысы да эшләнгән, уенчыкларга кадәр бар. Бүлмә 50 пациентка исәпләнгән. Биредә авырулар берничә сәгать яталар, аннары аларны палаталарга күчерәләр.

Республиканың балалар реанимация-консультация үзәге тәүлек буе эшли. Авыр хәлдәге авыруларны хастаханәгә вертолетларда, реанимобильләрдә тиз арада китереп җиткерү мөмкинлеге тудырылган. Ата-аналар өчен дә барлык шартлар бар.

– Без хастаханәдә инде ике ел дәваланабыз. Авыруыбыз үпкә белән бәйле. Бала янына теләсә кайсы вакытта килергә була, янында калырга да мөмкин, палаталар уңайлы. Ачык йөзле, тәҗрибәле табиблар, шәфкать туташларына бик рәхмәтлебез, – ди баласы янында кизү торучы аналарның берсе.

БАЛАЛАР ЯТКАН КИЛЕШ ҮСӘ

Хастаханәдә паллиатив ярдәм күрсәтү бүлеге эшли. Бу төшенчә безнең республикага әле соңгы елларда гына килеп керде. Паллиатив ярдәм – кешегә гомеренең соңгы мизгелләрендә булышу дигән сүз. Төп максат – дәвалап булмый торган диагнозлы балаларны тәрбияләү, аларның тормыш шартларын яхшырту, хәлләрен җиңеләйтү. Ясалма сулыш аппаратына тоташтырылган балалар яткан килеш үсә, ашый, эчә, хәтта туган көнен дә уздыра. Без килгән көнне бер баланың койкасы янында шарлар эленеп тора иде. Күптән түгел бер яшь тулган көнен билгеләп узганнар икән.

– Бу балалар яшәми, ләкин исән. Элек катлаулы диагноз куелган сабыйлар арасында үлем очраклары күп иде, бүген шул рәвешле аларның яшәү озынлыгын озайта алабыз. Авыру балаларның туганнары, якыннары, әти-әниләре өчен дә рухи ярдәм мөһим. Алар кайда булсалар да, балалары өчен тыныч. Балалары янына күңелләре кушкан чакта килә алалар, төнләме, көндезме – ишекләр һәрчак ачык, – ди реанимация хезмәте җитәкчесе, балалар анестезиясе һәм реаниматологиясе буенча Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгында баш белгеч Игорь Закиров.

Табиб фикеренчә, мондый дәвалап булмаслык авыруларга китергән сәбәпләрнең күбесе экология, йөклелек чорындагы проблемалар, бала тудырган чактагы өзлегүләр белән бәйле. Ничек кенә булмасын, паллиатив ярдәмгә мохтаҗ сабыйлар саны арта баруы бик кызганыч.

– Иң мөһиме – балалардагы авыруларны карында чакта ук ачыклап, дәвалап өлгерергә кирәк, – ди Игорь Закиров.

Республика балалар клиник хастаханәсе һәр баланы кайгырта. 40 ел элек ачылган хастаханәне бүген чит илдә дә беләләр. Һәр пациентның гомере өчен табиблар бердәм команда булып көрәшә. Иң зур җиңү – баланың савыгуы, елмаюлы карашы.

РЕСПУБЛИКА БАЛАЛАР КЛИНИК ХАСТАХАНӘСЕ САННАРДА

*Хастаханәдә **2157** хезмәткәр эшли: **438** табиб, **959** шәфкать туташы, **14** Россиянең һәм Татарстанның атказанган табибы. Ел дәвамында **900** студент, аспирант, ординатор, курсант биредә тәҗрибә туплый. Хастаханәдә эшләүче **100**дән артык хезмәткәр Европа һәм Американың алдынгы клиникаларында укулар узган.*

Рөстәм Миңнеханов эшкуарларны Эшмәкәрлек советына җыя

Июль аенда Татарстанда Президент карамагындагы Эшмәкәрлек советының киңәйтелгән утырышы узачак.

Әлеге утырышта теләгән һәр эшкуар катнаша ала. Рөстәм Миңнеханов, эшлекле даирәләр белән, аларны кызыксындырган актуаль мәсьәләләр турында сөйләшергә планлаштыра. Утырышта катнашырга Татарстанның бөтен районнарыннан да эшкуарларны чакыралар.

Эшмәкәрлек советы ул – эшкуарлар белән хакимият органнарының аралашу мәйданы.

2015 елда барлыкка килгән Совет шушы узган вакыт эчендә 70тән артык проект төзеде, бу эшкә 3 меңнән күбрәк эшкуар, 250дән артык хакимият органы вәкилләре җәлеп ителде.

Моңа кадәр Татарстан Президенты рәислегендә дүрт киңәйтелгән утырыш уздырылды. Аларда, мәсәлән, авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә Татарстанның барлык районнарыннан да фермерлар катнаша алырлык гадел шартлар булдыру турында карар кылынды, 1 меңнән азрак кеше яшәгән авылларда эшкуарлар өч елга онлайн-кассалар урнаштырудан азат ителде һәм башка мөһим мәсьәләләр хәл ителде.

Июльдә бишенче киңәйтелгән утырышта да Советның проектлар төркемнәре лидерлары Татарстанда бизнес өчен көнүзәк мәсьәләләрне күтәрәчәк. Бу юлы агач эшкәртүчеләрнең проблемалары, балаларны пассажир буларак йөртүдә артык чикләүләрне бетерү, кече эшкуарлыкка күзәтчелек басымын киметү кебек мәсьәләләр каралыр дип көтелә. Советка тема, идея яки проект тәкъдим итәр өчен, түбәндәге телефонга шалтыратырга: **+7 (843) 210-15-88** яки электрон почта аша **(sovet@sovet.tatar)** язарга мөмкин.

Тимур НОГМАНОВ, Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил:

– Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе буенча оештырылган Эшмәкәрлек советы – ачыклылык принцибы буенча төзелгән яңа структура. Теләсә кайсы эшкуар үз идеясен, проектын яки чишелеш таләп иткән актуаль проблеманы тәкъдим итеп, Совет эшендә катнаша ала. Совет экспертлары һәр тәкъдимне тикшерә, без хакимият органнары белгечләрен дә җәлеп итәбез. Татарстанның барлык эшкуарларын актуаль мәсьәләләрне билгеләргә чакырам.

ӘНИЕМНЕҢ җылы кочагы

«Син курыкма, мин сине хәзер серле дә, матур да булган «теге дөнья»га, әтиең янына алып китәм, – дип ягымлы гына эндәште ул миңа, – ул сине бик ярата, сине анда би-ик сагынып көтә...»

ӘТИСЕЗ БАЛАЧАК

Бу сүзләрдән соң корт чаккандай булып китте. Яшен тизлеге белән, аннан нәни кулларымны тартып алдым да ялвара башладым:

– Юк, кирәкми, минем барасым килми, зинһар, мине анда алып китә күрмә, мине газиз әниемнән аерма.

Ул тагын минем кулларымнан тотарга тырышты, ә мин чәбәләндем, тыпырчындым һәм зәңгәрле-яшелле тавышлар белән елый-елый, кычкырып ук җибәрдем:

–Җибәр мине, минем ү-л-ә-сем кил-ми-и!!!. Ишетәсеңме, ү-л-ә-сем кил-ми-и!!!

...Ахрысы, мин шундый каты кычкырганмын, үз тавышымнан үзем куркып уянып киттем.

...Бу вакытта миңа нибары дүрт яшь иде. Минем бу фани дөньяны танып белүем дә шушы мизгелдән башланды булса кирәк. Моңа кадәр хәтеремдә бер генә күренеш сакланган, ул да булса, узган ел хәрби оркестрлар белән әтиемне соңгы юлга озату...

Шушыннан башлап, кисәк кенә, минем өчен сабыйлык чоры узып та киткән кебек булды. Авылда гына түгел, районда, хәтта республика күләмендә дә әтием турында халык авызыннан гел яхшы сүзләр генә ишетеп торсак та, кешеләр арасында бер-берсен «өнәп бетермәү» дигән нәрсә дә бар бит әле. Андыйлар, җае чыккан саен, әтиемә булган мөнәсәбәтләрен миңа булса да белгертеп торырга иренмәделәр. Әтием заманының иң алдынгы фикер ияләренең берсе булган: мәктәп директоры, бер үк вакытта колхозның партоешма секретаре, яхшы гармунчы, республикада билгеле керәшен, запастагы офицер...

Үземне кыерсыттырмадым. Чаялыгым күбрәк әтисезлегем аркасында үз-үземне саклау, яклау инстинкты гына булгандыр.

ТОЛЛЫК АЧЫСЫН ЙОТЫП

Әниебез 32 яшендә тол калып, авылда ике баланы (берсенә – өч, ә икенчесенә– биш яшь) аякка бастырды. Нинди генә михнәтләр күрмәгән, ирсезлекнең бөтен газапларын үзенең тыныч табигатенә, акыл-фигыленә сыйдыра алган. Гомере буе гел игелекләр генә кылган әниемә әле күптән түгел генә 91 яшь тулды. Үземне иң бай кешеләрдән дә баерак хис итәм. Минем иң зур байлыгым – бөтен гомерен яшь буынны тәбияләүгә биргән, гомере буена Зәй районы Федоровка авылы китапханәсе мөдире булып эшләгән әнием – Ксения Андреевна ул. Минем әнием, чын мәгънәсендә, Әни образына тулысы белән туры килә торган монументаль әни.

Сөекле әниемнең
Борчыгандыр җанын
Күңелемнең көйсез һәр чагы.
Еласам, юаткан,
Иркәләп уяткан
Әниемнең җылы кочагы.

(Мөнир Мазунов шигыре)

Әтиемнең вафатына бер ел тулу уңаеннан чәйгә дип авыл карчыкларын чакыргач, әниемне диндарлыкта гаепләп, партия райкомына шикаятьләр яздылар. Тикшерүләр башланды. Әниемне «Коммунизмны төзүченең мораль кодексы»на тап төшерүдә гаепләделәр. Ә инде ачык партия җыелышларының берсендә әнием:

– Әйтегез әле, авылдашлар, һәр елны бөтен прогрессив кешелек дөньясы даһи Ленинның үлгән көнен билгеләп үтә, ә тол хатынның үз иренә булган ихтирамын, тугрылыгын күрсәтүе, аның үлгән көнен билгеләп үтүе ул шулай бик зур гаеп эшмени? – дигәч, бу борчулар нык ук төссезләнеп, тоныкланып калды кебек.

Әниебезнең безгә булган йогынтысы тормышта шактый уңайсызлыкларны, мәшәкатьләрне җиңеп чыгарга ярдәм итте дә инде. Әлмәт төзүче-инженерлар көллиятенең укытучысы апам Светлана Григорьевнаның фәкать үз тырышлыгы белән «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек булуы гына да әниебез тырышлыгының җимеше булды.

ХЫЯЛДАГЫ ГАРМУН

Әнкәемнең безгә эшләгән игелекләрен сөйләп тә, үлчәүдә үлчәп тә бетерерлек кенә түгел. Шулай да алар турында бер-ике эпизодны искә төшереп узасым килә. Әтиемнең: «Әгәр малаем туса, соңгы телем икмәгемне сатып булса да, гармун алып бирер идем», – дигән хыялын әнием, ничек итсә итте, әмма тормышка ашырды бит.

Ел фасылларының искиткеч күңелле сихри бер мизгеле. Гыйнвар ае. Икенче класста укып йөргән чагым. Озын тәнәфескә чыкканда, безнең гаиләдә бәйрәмнең сәбәпчесенә генә күрсәтелә торган хөрмәтне искә төшереп, кәефемнең тагы да күтәрелүен тойдым. Озын тәнәфестә мәктәптән өч өй аркылы гына булган өебезгә әбәткә кайтканда да, мин ул араны өч кенә таптык сикергән кебек булдым. Мин, ишектән килеп керүгә, әниемнең мичтән тартып чыгарган чуеннан тәлинкәләргә бүлеп, инде өстәл өстенә дә куеп өлгерелгән итле бәрәңге шулпасының хуш исеннән авыз суларының агып китүен тойдым. Ә өстәл өстендәге бер тәлинкә янында туган көн бәйрәмнәрендә генә куела торган әтиемнең көмеш кашыгын да күргәч, минем башым бөтенләй түшәмгә тиде. Үзем ашыйм, үзем күз кыры белән генә өй эчен карап чыгам, ләкин анда бүләккә охшаган берни дә күренми. Шулай ук берни дә бүләк тә булмасмы икәнни?

Көннең икенче яртысында укуның рәте булмады, уйларым гел шул бүләк тирәсендә чуалды. Укудан кайтканда, тыкрыктан үзебезнең урамга борылган гына идем, ни күзем белән күрим, безнең капка төбеннән җигелгән атка тулып киеп утырган әнием, атны юрттырып, Мәлем ягына таба китеп бара иде. Күздән югалганчы, аның артыннан кычкырып та, йөгереп тә карасам да, әнием атын туктатмады.

«Җигүле атка утырып, әнием кая китте икән соң, әллә гармун алыргамы? – дигән уй сызып узды. –Чыннан да әгәр шулай булса? Мин шатлыктан нишләрмен икән?.. Булмас ла. Каян акча алсын ди ул?» Шундый уйлар белән борылып, мин өйгә кайтып кердем. Өй эчендә нинди сер бар иде. Түзәр әмәлем калмагач, балачак дустым Мәтебей дәдәйнең Колясына киттем. Аның белән чаңгылар тагып, әниемнең каршысына чыккан идек тә, урман эченә керергә бүреләрдән курыктык. Караңгы да төште, ә атка утырган әниемнең урман авызыннан чыкканы һаман күренмәде. Кайттым да йокларга яттым. Ә икенче көнне уянып китү белән, күзем урындыктагы гармун футлярына төште. Футлярны кыюсыз гына ачып җибәрсәм, ни күзем белән күрим – әле краска исләре дә очып бетмәгән өр-яңа матур гармунны күреп, беркавем өнсез калдым. Менә нинди икән ул син, күпме йокысыз төннәр буена хыялланган минем гармуным... Гармунны савытыннан сак кына алдым. Тезләремә куйдым. Күрекләрен сузып карадым. Ә аннан соң, телләрен моңга мана-мана, әтиемнең иң яраткан көйләреннән берсе «Рамай»ны чыгарырга маташтым... Бу минутларда мин үземнең кичерешләремне сөйләп тә, язып та аңлатып булмаслык хәлдә идем.

«Иртүк торып гармун уйнамыйлар, куй гармуныңны» – дигән шелтәсе дә, ә соңрак:

«Таңнарыңа гармун уйнама,
Моңлы булырсың, балам,
Бу дөньяда моңсызлар күп,
Ниләр кылырсың, балам?» –

дигәне дә әле булса күз алдымда. Соңга табарак Әнгам Атнабаевның бу сүзләренә җыр да яздым. Җырның исеме дә «Таңнарда гармун уйнама» дип аталды.

МИН – АТКА АТЛАНГАН КОМАНДАРМ

Керәшеннәрнең яз көннәрендә генә уза торган бик матур яфрак бәйрәме – «Торыйсын» бар. Әнием, шушы бәйрәмгә туры китереп, миңа велосипед алып бирде. Шул матур, ялтыравыклы велосипедка атланып җилләр уйнатып авыл урамнары аша үткәндә, мин үземне атка атланган, дошманнарга каршы баручы легендар командармнар кебек хис итә идем. Ә әнием бу минутларда, мине бәхетле итә алганы өчен, үзен бәхетле итеп сизгәндер, мөгаен... Шушы хатирәләр аша гына да әниебезнең бөтен яшәеше, тормышының бөтен яме гел без булуын яхшы ук аңлыйбыз. 32 сум хезмәт хакы белән 54 сумлык велосипед алып бирү, әлбәттә, әниемне күп уйланырга мәҗбүр иткәндер. Ул вакытларда әле әниемнең үзенә дә нибары 35-38 яшьләр генә булган бит. Юкса, бу искиткеч мөлаем да, гүзәл дә, яшь тә ханымның үзенең генә дә хыяллары булгандыр... Аның үзенең дә берәр яңа күлмәк, туфли йә булмаса бераз күзгә күренерлек өс киеме алып киясе килгәндер.

32 сум хезмәт хакы белән 54 сумлык велосипед алып бирү, әлбәттә, әниемне күп уйланырга мәҗбүр иткәндер. Ул вакытларда әле әниемнең үзенә дә нибары 35-38 яшьләр генә булган бит. Юкса бу искиткеч мөлаем да, гүзәл дә, яшь тә ханымның үзенең генә дә хыяллары булгандыр... Аның үзенең дә берәр яңа күлмәк, туфли йә булмаса бераз күзгә күренерлек өс киеме алып киясе килгәндер

КИТАПХАНӘ ҖЫЛЫСЫ

Әни эшләгән вакытларда халык арасында массакүләм агитация чаралары бик киң алып барыла иде. Колхоз партоешмасы кушуы буенча бөтен агитация эшләре әниемә йөкләнгән иде. Телефон баганасы саен диярлек әниемнең зәвыклы итеп эшләгән лозунглары, транспарантлары беркетелгән булыр иде. Терлекчелек фермаларын, җәйләүләрне дисеңме, аларны бизәүне шулай ук әнием башкарды. Боларның барысы да «з-у-р» рәхмәтләргә эшләнде. Ә ул эшләгән китапханәдәге системалы тәртипкә исең китмәле иде. Шуның өчен дә укучы балалар күбебез гел шунда җыелып ята идек. Ә анда үзе бер могҗиза! Бик салкын кышкы көннәрдә шул чиста-пөхтә җылы китапханәнең стеллажлары арасында китап укуның рәхәте, ләззәте әле хәзер дә минем күңелемдә бетмәс-төкәнмәс җылы кичерешләр уята. Башлангыч музыкаль белемне дә мин шул китап стеллажлары арасында алдым дисәм дә, һич тә ялган булмас. Зиннур Гыйбадуллинның «Баянда уйнарга өйрән» дигән китабы минем беренче музыкаль әлифбам булды. Яңа кайткан иң беренче китапларны да әнием, башта үзе карап чыгып, апам белән безгә тәкъдим итә иде.

Авыл яшьләре, гомумән авыл халкы белән спектакльләр әзерләү, аларны күрше авылларда да күрсәтүләр дисеңме... Китап укучылар конференцияләре, яңа кайткан китапларга презентацияләр уздырымы – болар барысы да әнием өстендә иде.

Шактый еллар буена әниләргә багышланган бер матур җыр чыгару хыялы белән яндым. Һәм менә, ниһаять, бу хыялым тормышка ашты булса кирәк. Сүзләрнең эчтәлегенә, мәгънәсенә тәңгәл килерлек, матур яңгырашлы, шул ук вакытта үземнең күңелгә дә ошаган бер көй килеп чыкты кебек... Ул җыр Илдар ага Юзеев сүзләренә «Әнкәемнең туган ягында» дип аталды.

Җиһанны иңләп, җиргә тагын ямьле җәйләр килде. Чал чәчле әнием белән кунак бүлмәсендә радиодан концерт тыңлыйбыз. Әнә аның яраткан «Яшьлегемә кире кайтыр идем» дигән җыры яңгырый. Үзем җыр тыңлыйм, ә үзем әниемне күзәтәм. Фикер йөртүе, үз-үзен тотышы, акыл-фигыле белән ул миңа бер тамчы да үзгәрмәгән кебек. Мин, 8нче классны тәмамлагач та, аны ничек бер ялгызын өйдә калдырып чыгып киткән булсам, ул һаман да шулай. Шул ук тыныч холык, сүзләрендә һаман да шул ук тапкырлык, хаклык, ә йөзендә эчкерсез елмаю. Озак та үтми, ниндидер саргаеп беткән кәгазь битләре, документлар алып чыгып күрсәтә башлый. Ул гүя үзенең бөтен белгәнен миңа калдырып китәргә ашыга кебек...

– Йа Хода! Үзенең исәнлеге һәм бөтен чынбарлыгы белән безне бары шатландырып кына торган, безгә яшәргә көч биргән әниебезгә тагын аның хәленнән килгәнчә гомер бир-с-ә-н-ә... – дип галәмгә кычкырасым килә.

Давыллы көннәрдә
Саклаган җилләрдә
Күкрәгенә кысып кем тагын?
Кадерләп үстергән,
Яшәргә көч биргән
Әниемнең җылы кочагы...

(Мөнир Мазунов шигыре)

Геннадий **МАКСИМОВ**,
баянчы, композитор.

Күркәм җирнең асыл улы

Татар тарихын фән буларак өйрәнү мөһим булган кебек үк, аның үткәнендә булган аерым вакыйгаларны, халык арасында йөргән хикәятләрне, аерым урын, бина тарихларын өйрәнү, аны буыннан-буынга тапшырып калдыру – безнең киләчәккә булган әманәтебез. Һәр төбәкнең тарих белән янып-көеп йөрүче, үз җирен, халкын яратучы, аның киләчәге өчен бар булганы белән уртаклашырга әзер булган мөхтәрәм затлары була.

Әтрәч тарихының сагында – Мөнир Вәлиев.

Без, профессиональ тарихчылар, әлеге төбәкчеләр белән аралашып торабыз, хезмәттәшлек итәбез. Язмыш мине шундый кеше – милләтнең бер хадиме Әтрәчтән Мөнир абый Вәлиев белән очраштырды. Заманында тарихчы Гайнетдин Әхмәрев мирасын өйрәнгәндә, мин Әтрәч дигән авылның Тау ягындагы тарихи җирлек икәнен, анда Шиһабетдин Мәрҗанинең әтисе белән килгәнен, борынгы Болгар чорыннан калган кабер ташларының сакланып калуын һәм дә ул җирлек Болгар дәүләтенең акча сугу урыны булганын да белә идем. Әле җитмәсә, ул минем кече Ватан – Тау ягы. Менә шундый төбәк кешесе Мөнир абый. Аның сөйләгәннәреннән Тау ягы тарихы минем күз алдында тернәкләнде. Казан арты тарихын инде шактый белсәк, бу як тарихы хакында мәгълүматыбыз чикле. Моны тарихчылар да таныр, чөнки ул якка караган документлар Казан артына караганнардан күпкә аз.

Зур Әтрәч авылында туып-үсеп, гомере буе шул авылда балаларга белем биргән Мөнир абый инде телгә дә алынмый башлаган борынгы Болгар шәһәре Шонгаты урыныңдагы Зур һәм Кече Әтрәч авылларын таныта гына түгел, шул җирдәге тарихны саклый, авылны бетермәс, аны үстерү өчен, чиновниклар ишеген шакый, галимнәр белән элемтәдә тора. 2016 елда Тәтеш шәһәрендә борынгы Шонгаты җире тарихына багышланган фәнни конференция дә уздыруга ирештеләр. Анда билгеле археологлар, Рафаэль Хәкимов җитәкчелегендә тарих институты галимнәре үзләренең бу төбәк тарихы белән бәйле соңгы тикшеренү нәтиҗәләрен тәкъдим иттеләр.

Борынгыдан халык телендә «Мең өйле Шонгаты» дип аталган җирлектәге халыклар, XX йөз башы тарихчысы Гайнетдин Әхмәрев язуынча, «Болгар шәһәре белән кыз биреп, кыз алышканнар». Кайчандыр шәһәр булып, туздырылып беткән шушы җирлектәге кабер ташлары ятим булып, ватылып-тузып ята, XX йөз башында ук Гайнетдин Әхмәрев алар тирәсендә көтү йөргәнен, каберстанның кадерсезләнүен яза. Күпме таш юкка чыккан, алар белән күпме мирас, күпме тарих киткән. Кечкенәдән Болгар җиреннән атлап йөргән мөгаллим Мөнир абый да моңа битараф була алмый. Аның тырышлыгы белән башланган бу эш, татар халкының мөхтәрәм заты Туфан ага Миңнуллин кулына күчкәч, җиренә җиткерелмиме инде! Үзе дә шул Тау ягыннан булган, туган җирен ихластан яраткан Туфан ага бу хакта ишетү белән, үз хисабына борынгы зур зиратны тирәләп алырлык тимер койма эшләтә. Әтрәч җирлегендә ел саен, 2006 елдан башлап, «Әтрәч укулары» уздырып киләләр. Быел исә әлеге чара 9 июльдә булачак. Анда башта зират янында бабайлар рухына дога укыла, аннан Әтрәчнең шифалы сулы чишмә буенда, тау итәгендә «Әтрәч укулары» үтә. Бу җыен гади генә түгел. Монда ерак-ераклардан тамырлары белән шушы авылдан булган кешеләр җыела. Иң мөһиме – үз тарихлары барлыйлар, андагы бала-чага бәләкәйдән үк үзенең бәрәкәтле, зур тарихы булган җирдә икәнен белеп үсә, туган җире, халкы белән горурлана. Чишмә суыннан кайнатылган чәй, корбан итеннән учакта пешерелгән шулпа – болар барысы да халыкның үзенеке. Башланган вакытта шактый тыйнак кына күренгән әлеге җыен хәзерге вакытта бөтен Тау ягы җыенына әйләнеп килә. Бу төбәкнең барлык районнарыннан да дин әһелләре, зыялылар җыела, Казаннан кунаклар кайта анда. Җыенда Зур Әтрәчтә бабасы мулла булып торган Фуат Әбүбәкеровның скрипкада уйнавы, Миңгол абый Галиевнең моңлы көйләре йөрәкне айкап алып, уйларны борынгы Болгар чорына алып кереп китә, күзгә мөлдерәп яшь тула, халкыбызның үткәне, газабы, кайгысы-шатлыгы – барысы берьюлы хәтергә килә. «Әтрәч укулары» барышында археологлар, тарихчылар, төбәкчеләр, җәмәгать эшлеклеләре халык алдында бу төбәк тарихына караган үз табышлары, ачышлары хакында чыгыш ясыйлар.

Әтрәчлеләр инде «Шонгаты» дигән оешма да булдырдылар. Аның директоры да, идея чыганагы да, эшнең авырын тартучы да – Мөнир абый. Мондый эшкә хөкүмәтнең бер оешмасыннан да бер тиен кермәгән хәлдә, боларны башкару, нидер эшләү катлаулана, кайвакытта мөмкин дә түгел. Әле ярый халкыбыз, матди мөмкинлеге булган затларыбыз бар.

Мөнир абыйга телефоннан шалтыратсаң, «Казанга менеп төшәм әле тиздән, күрешербез», – дип кенә сөйләшә. «Казанга менеп төшүнең» бик тиз генә түгеллеген исәпкә алсаң, инде олы яшьтәге Мөнир абыйның авыл тарихы өчен түккән көчен, вакытын, туздырган пенсия акчасын күзалдына китерү кыен түгел. Ярый әле аның терәге – фикердәшләре, туган җирне яратучы ярдәмчеләре, аны аңлаучы җәмәгате Әлфия апа, мөгаллимә булып эшләүче кызлары бар.

Болгар тарихы Болгар шәһәре белән генә тәмамланмый. Бу тарих белән без генә түгел, ә күршеләр дә, ислам дине таралышының иң төньягы буларак мөселман дөньясы да кызыксына. Булган кадәр истәлекләр ярдәмендә булса да күтәрергә иде тарихны, күрсәтергә иде аны!

Эльмира СӘЛАХОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Яңа һәм кулланышта булган металл (пенал) гаражлар сатабыз. Теләсә нинди үлчәмдә.
Китереп бирү бушлай. Бәясе 27 мең сумнан башлана. Тел.: 8-800-700-90-91
Реклама

НУЖНЫ ДЕНЬГИ –
плохая кредитная история –
ты в черном списке –
отказывают в кредите? ЗВОНИ!
8-904-666-68-68, 8-951-893-63-22
ООО «Микрокредитная компания «АльтернативА» ОГРН 1141690089650
Реклама

www.shahrikazan.com
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
twitter.com/shahri_kazan
ok.ru/shrikazan
instagram.com/shahrikazan

РЕКЛАМА
ООО «Дом окон» реализует окна (ПВХ, алюминий), потолки, балконы по разумным ценам. Тел. 8-927-044-95-96

Требуется менеджер по продажам кормовых добавок для сельского хозяйства. Образование: зоотехния, ветеринария, знание кормопроизводства, опыт работы в данной сфере от 1 года. Зарплата: оклад + % от продаж (по итогам собеседования), компенсация сотовой связи, амортизации автомобиля и ГСМ, оформление по ТК. +7-919-635-57-00, Резида Мансуровна
Реклама

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ

Кадастровым инженером Латыповым Ниязом Диллусовичем (420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15, эл.почта s2495066@yandex.ru, тел.89270393119, квалификационный аттестат 16-12-503) выполняются кадастровые работы в отношении земельных участков с кадастровым номером 16:16:083601:1059, расположенный: Республика Татарстан, г.Казань, с/т «Овражек», участок 125 б и с кадастровым номером 16:16:083601:1087, расположенный: Республика Татарстан, г.Казань, СНТ «Овражек», участок 126.
Заказчик кадастровых работ: Федорова Нина Петровна (г.Казань, ул.Мира, д.43, кв.17).
Согласование местоположения границ проводится с установлением границ земельных участков на местности путем проведения собрания, которое состоится 23 июля 2017 года в 9 часов 00 минут по адресу: г.Казань, с/т «Овражек», участок 125 б.
С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г.Казань, ул.Главная, д.62/15.
Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 24 июня 2017г. по 21 июля 2017г. по адресу: 420075, г.Казань, ул.Главная, д.62/15.
Номер кадастрового квартала, в границах которого расположены земельные участки, в отношении которых проводятся кадастровые работы, и смежные земельные участки: 16:16:083601 (г.Казань, садоводческое некоммерческое товарищество «Овражек»).
При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

Чайнворд

«Ураза гаете мөбарәк булсын!»



Нияз Бишбалта төзеде.

1. Коръән-Кәримнең беренче сүрәсе.
2. Иң әүвәл яратылган кеше.
3. Казанда Г.Баруди нигез салган, җитәкчелек иткән мәдрәсә.
4. Коръән-Кәримнең 36нчы сүрәсе.
5. Гыйбадәт.
6. Ислам дине нигезенең бер терәге.
7. Юыну-пакьләнү.
8. Җепкә тезелгән йөз төймәдән гыйбарәт җайланма (аның һәр төймәсен Аллаһка мактау сүзен әйтеп артка шудыралар).
9. Мөселманнарда гыйбадәт кыла торган изге урын.
10. Олуг фәрештә.
11. Кешеләрнең тәкъдире язылган такта.
12. Аллаһы Тәгаләне искә алу, олылау.
13. Ураза ае.
14. Мөселманнарның өйләнешү йоласы.
15. Шәригатькә каршы килгән, тыелган нәрсә.
16. Мөхәммәд (с.г.с.)нең Рәҗәб ае төнендә күккә ашуы.
17. Мәетне Ислам дине кушканча күмү йоласы.
18. Үлгәннән соң булачак дөнья.
19. Шәригать кануннары буенча рәсми аерылышу.
20. Аллаһны танымау.
21. Мәгърифәтче, исламият галиме, ислахчы.
22. Ураза аенда авыз ачу.
23. Пәйгамбәр.
24. Кабердә мәет өчен урын.
25. Аллаһның берлегенә ышану.
26. Аллаһка ялварып, теләгеңне җиткерү.
27. Кояш баегач кыла торган гыйбадәт.
28. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) туган шәһәр.

Җаваплар.
1.«Фатиха» **2.**Адәм **3.**«Мөхәммәдия» **4.**«Ясин» **5.**Намаз **6.**Зәкят **7.**Тәһарәт **8.**Тәсбих **9.**Хаҗ **10.**Җәбраил **11.**Ләүхелмәхфүз **12.**Зекер **13.**Рамазан **14.**Никах **15.**Хәрам **16.**Мигъраҗ **17.**Җеназа **18.**Ахирәт **19.**Талак **20.**Көферлек **21.**Курсави **22.**Ифтар **23.**Рәсул **24.**Ләхет **25.**Тәүхид **26.**Дога **27.**Ахшам **28.**Мәккә.

Банкка бурычны артыгы белән кайтармас өчен нишләргә?

Татарстан кредитлардан актив файдалану буенча 6нчы урында – республика халкы кибетләрдә кредитка товар ала, кредит карталарыннан, хәтта микрозаймнардан файдалана.

Банктан кредит алырга туры килгән очраклар һәркем белән дә була. Уңайсыз хәлгә калмас һәм кирәгеннән артыгын түләмәс өчен, нәрсәгә игътибар итәргә соң?

КИБЕТЛӘРДӘГЕ КРЕДИТЛАР

Сез кибеткә телевизор сатып алырга киләсез. Ләкин ошаган товарга акчагыз җитми. Шул вакыт сезгә «процентсыз рассрочка» тәкъдим итәләр, әйтик, 12 айга. Бик яхшы тәкъдим: 30 000 сум урынына яңа телевизор өчен ай саен нибары 3 000 сум түләячәксез. Әмма бу тәкъдимнең бер китек ягы бар – һәм аны, алда нәрсә көтәсен аңлар өчен, белеп торуың хәерлерәк.

Кибетләрдәге «процентсыз рассрочка» ул – чынлыкта гадәти процентлы кредит. 12 айга 30 000 сумлык телевизор сатып алып, сезгә аңа күбрәк: 30 000 + процентлар түләргә туры киләчәк. Ләкин кибет, сатып алучыны җәлеп итәр өчен, процентлар суммасын ташлама аша компенсацияли. Әгәр телевизор 30 000 мең сум, ә 12 ай өчен процентлар суммасы 6 000 сумны тәшкил итсә, кибет сезгә бу товарны 24 000 сумга сата. Нәтиҗәдә аны ташлама белән сатып алып һәм процентлар түләп, сез шул 30 000 сумны бирәчәксез. Отышлымы? Ярыйсы.

Ләкин өстәмә чыгымнар да бар: кимендә страховка һәм айлык түләүләр турында хәбәр итә торган түләүле СМСлар. Страховканы банк таләп итә, соңрак аңардан баш тартырга да мөмкин, ләкин аны, кагыйдә буларак, товарны сатып алгач 14 көн рәсмиләштерергә һәм моның өчен иминият компаниясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шулай ук кредитны түләү ысуллары алдан ук белешеп кую да комачауламый – һәр түләү саен тагын комиссия дә каралмаганмы?

Кибетләрдәге кредитның тагын бер кимчелеге – ул берникадәр чикләнгән, ягъни билгеле бер товарларга гына тәкъдим ителә яки, гомумән, барлык кибетләрдә дә юк. Шунысы да бар: 1 кредит – 1 сатып алу ул. Бүген – телевизор, ә бер-ике атнадан суыткыч сатып алдыгыз ди. Шулай итеп, сезнең – ике кредит килешүе, ике төрле түләүләр, ике страховка һ.б. барлыкка киләчәк.

Нәтиҗә: «процентсыз рассрочка» зур суммадагы сатып алулар өчен генә уңайлы, шул рәвешле сумманы берничә айга бүлеп була. Ләкин өстәмә чыгымнар аркасында артыгын түләүдән барыбер котылу мөмкин түгел.

КРЕДИТ КАРТАЛАРЫ

Уңайлы ягы – билгеләнгән лимит кысаларында теләсә никадәр сатып алулар башкарырга була. Банкоматтан акча да алырга мөмкин, ләкин инде бу очракта комиссия тотыла. Гадәттә ул 200-300 сум күләмендә була, һәм, әйтергә кирәк, нибары 1000 сум алсагыз да комиссия түләтәләр.

Шулай ук кредит картасының процентсыз чоры (грейс-период) бар. Сатып алган көннән башлап, берничә көн дәвамында процент саналмыйча тора: күп кенә банкларда процентсыз чор 120 яки хәтта 200 көнгә җитә. Әмма бу очракта да кайбер нечкәлекләрне онытмавың хәерле.

Кредит карталарында стандарт грейс-период – 40 көннән 60 көнгә кадәр. Әгәр 100 яки 200 көн тәкъдим итәләр икән, еш кына монда төрле чикләүләр була. Мәсәлән, озын грейс-период бер генә сатып алуга кагылырга мөмкин, ә аның аша икенче тапкыр сатып алу башкаргач, ул стандартка, әйтик, 40 көнлегә әверелә. Шулай ук моның ничек эшләвен аңларга кирәк: әйтик, сезнең картаның процентсыз чоры – 100 көн, һәм сез нәрсәнедер 1 июньдә сатып алдыгыз ди. Бу тотылган акчаны тулысынча 8 сентябрьгә кадәр кертергә кирәк. Әмма әле бу 100 көн дәвамында сез банкка берниндИ акча түләмисез дигән сүз түгел. «Минималь түләү» бар: айга бер тапкыр сез билгеле бер сумманы кертәсез. Әгәр ул акчаны кертмәсәгез яки соңартсагыз – грейс-период тәмамлана һәм процентлар санала башлый.

Нәтиҗә: кредиткалар уңайлы, ләкин шартлары бик үк ачык түгел. Алар белән файдаланырга була, ләкин бик сак кына. Шулай ук еллык хезмәт күрсәтү бәясенә (елына 400-500 сумнан берничә мең сумга кадәр җитәргә мөмкин), СМС өчен түләүләргә, онлайн-банкның түлы версиясе дә игътибар таләп итә.

ПРОЦЕНТСЫЗ РАССРОЧКА КАРТАСЫ

Татарстанда «Совесть» дип аталган яңа карта апрель аенда пәйда булды. Ул сәүдә челтәрләрендә, интернет-кибетләрдә, рестораннарда бурычка сатып алырга һәм ул бурычны процентларсыз кайтарырга мөмкинлек тудыра. Бер генә шарт – түләүләрне вакытында кертергә кирәк.

Процентлар юк, бу – чын хәлме? Монда берниндә дә хәйлә юк, бөтен эш – картаның үзенчәлегендә. Гадәти банклар процентлардан табыш күрә, бу – аларның төп керем чыганагы. Ә рассрочка картасының акча эшләү чыганагы башка. «Совесть» хезмәттәшлек иткән кибетләрдән табыш ала, чөнки кешеләр рассрочка картасы белән алардан товар сатып ала. Әлеге схема буенча клиент, картадагы акчаны бурычка файдаланып, процентсыз кайтара ала. Товарның бәясе үзгәрми, ул гадәти акча белән түләгәндәге кебек кала.

Рассрочка чоры – 12 айга кадәр (һәр кибеттә төрлечә). 25 мең сумга 5 айга кием сатып алдыгыз ди. Ай саен 5әр мең сум түлисез. Вакытында түләп барсагыз, процентлар булмый. Айлык түләүне соңартсагыз, бер тапкыр 290 сум штраф салына (кредиткалардагы ишерен процентлар урынына). Әгәр 5 айдан соң бөтенләй түләмәскә уйласагыз, бурыч суммасына 10 процент өстәләчәк, әмма бу инде соңгы чара, ул үзен намуссыз тоткан кешеләргә кагыла.

Түләүләрне сайтта шәхси кабинеттан карап барып була. Система үзе барлык сатып алулар өчен бердәм түләү формалаштыра һәм СМС белән хәбәр итә.

Монда бер үзенчәлек бар – карта бары тик «Совесть» хезмәттәшлек челтәрендә генә эшли. Шулай да бу – Россия буенча 12 меңгә якын кибет дигән сүз, ә Татарстанда танылган «М-Видео», «Связной», «Иль де Ботэ», «Аэрофлот» кебек федераль брендлар да, яраткан җирле «Бәхетле» һәм «Казанские аптеки» челтәрләре дә бар.

Картадан акчаны банкомат аша алып булмый, ләкин еллык хезмәт күрсәтү, СМС һәм онлайн-банктан файдалану – бушлай. «Совесть» картасын тотучыларда башка өстәмә чыгымнары юк.

Йә ничек, электроника кибетеннән чикле күләмдәге товарлар арасыннан эре сатып алу башкарырга телисезме? Сезгә кибеттәге кредит туры килер. Картадан, комиссия белән булса да, акча аласызы киләме? Кредитка ярап куя. Әгәр хезмәттәшләр челтәрендә процентларсыз сатып алулар башкарасыгыз килсә, процентсыз рассрочка картасына игътибар итегез.

«Совесть» Кичектереп түләү картасы ярдәмендә партнерлык челтәренә керә торган сәүдә-хезмәт күрсәтү предприятиеләрендә әйбер сатып алганда, КИВИ Банкы (АҖ) кредит бирүнең ташламалы чоры («кичектереп түләү вакыты») турындагы шарт белән кредит («кичектереп түләү») тәкъдим итә, аның дәвамында кредиттан файдаланган өчен процентлар алынмый. «Совесть» Кичектереп түләү картасының эмитенты – КИВИ Банкы (АҖ), Россия Банкының 2241нче номерлы лицензиясе. Реклама

АФИША
26 ИЮНЬ-2 ИЮЛЬ

ТЕАТР

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

26 июнь «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова)
Башлана: 18.30
28 июнь «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
29 июнь «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 200-1000 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

29 июнь «Ханума»
(олылар өчен спектакль)
Башлана: 18.00
1 июль «Теремок» (С.Маршак)
Башлана: 11.00, 13.00
2 июль «Хаврошечка» (Л.Савчук)
Башлана: 11.00, 13.00
2 июль «Тамчылар» мавыктыргыч әкият
Башлана: 11.00
Билет бәясе: 200-300 сум

«БОЛАКТА» ЯШЬЛӘР ТЕАТРЫ
(УҢ ЯК БОЛАК УРАМЫ, 13)

27 июнь «Скамейка»
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 150-600 сум
28 июнь «Мсье Ибрагим»
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 150-700 сум
28 июнь «Неспящие в Лондоне»
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 150-700 сум
29 июнь «STAND UP» *кафе-театр*
Башлана: 20.00
Билет бәясе: 800-1600 сум
30 июнь «Golden boys»
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-800 сум

КИНО

В.АКСЕНОВ СКВЕРЫ
(«МИР» КИНОТЕАТРЫ АРТЫНДА)

28 июнь «Коробка» (режиссер – Эдуард Бордуков)
Башлана: 21:00
Керү ирекле

СПОРТ

ГОРЬКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ҮЗӘК МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ЯЛ ПАРКЫ
(ЕРШОВ УРАМЫ, 7)

1 июль «Parkrun» йөгерү буенча тренировкалар
Башлана: 9.00
Катнашу бушлай

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе.
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

Казанда – Кыргызстан мәдәнияте көннәре

tatar-inform.ru

Бүген Казанда Кыргызстан мәдәнияте көне утә. Программа кысаларында, казанлылар Кыргызстан сәнгать осталары концертын, кыргыз кинофильмнарын һәм сынлы сәнгать күргәзмәсен карый алачак. Әлеге чараларның барысына да керү бушлай.

– Мәгълүм булганча, күптән түгел Россия Президенты Владимир Путин белән Кыргызстан Президенты Алмазбәк Атамбаев очрашты. Шушы очрашу кысаларында, Россиядә мәдәният көннәрен оештырырга булдык. «Россиянең кайсы субъектларында булырга телисез?» – дигәч, без беренче чиратта Татарстанны күрәсебез килүе турында әйттек. Татарлар Кыргызстан мәдәнияте үсешендә зур роль уйный. Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә апаның татар милләтеннән икәнен барыбыз да яхшы белә, – диде кинорежиссер, продюсер, Кыргызстан кинематографистлары берлеге рәисе Садык Шер-Нияз.

Чараларның бер өлеше Мәскәүдә 20 июнь көнне узган инде. Татарстаннан кала, мәдәни чаралар тагын Башкортстанда уза. Садык әфәнде әйтүенчә, алар Казанга иң яхшы җырчылар – Кыргызстанның атказанган артисты, баш дирижер Рәхәтбәк Осмоналиев җитәкчелегендәге Зур дәүләт симфоник оркестры белән килгән. Концерт бүген Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында 19.00 сәгатьтә башлана. Биредә Кыргызстанның халык артисты Кәрим Турапов, атказанган артистлары Эльнур Самарбәков, Бактыбәк Ыбыкеев, халыкара конкурслар лауреатлары Заир Райымбәков, Айзирәк Момунова һәм башкалар башкаруында классик оперетталар һәм эстрада җырлары яңгыраячак.

Шунысын да искәртеп узарга кирәк: мондый чаралар Россиядә зур масштабта соңгы тапкыр 2003 елда үткәрелгән булса, Татарстанда бөтенләй уздырылмаган.

– Советлар Союзы заманында Кыргызстан мәдәнияте зурлап – декада буена бара иде. Ул вакытта 300 артист килгәнлеге истә калган. Миңа калса, мондый зур масштабта уза торган вакыйга шул заманнардан бирле уздырылмады. Казан безнең өчен кадерле. Тарихка күз салсак та, Кыргызстанның беренче дәреслекләре Казанда бастырылган һәм нәшер ителгән. Шуңа күрә Казан бездә һәрвакыт зыялы, рухи кыйммәтләр шәһәре буларак кузаллана. Гомумән, кыргызлар белән татарларны тел, дин, мәдәният берләштерә, – диде Садык Шер-Нияз.

Татарстанда Кыргызстан мәдәнияте көннәре координаторы Дарика Асылбашева әйтүенчә, «Хәзинә» милли сәнгать галереясы бүген 15.00 сәгатьтә ачыла һәм ул ун көн дәвамында эшләячәк.

Шулай ук «Мир» кинотеатрында да кыргыз кинофильмнары күрсәтеләчәк. Анда 2015 елгы Казан халыкара мөселман кинофестиваленең «Иң яхшы тулы метражлы фильм»ы булып танылган «Курманжан Датка» картинасын, Ник Жолдошевның – «Сутак», Руслан Акунның – «Перегон» һәм Нәргизә Маматкулованың «Сөйкө» фильмнарын карап булачак.

Кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, киләчәктә Кыргызстанда да Татарстан мәдәнияте көннәре узачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

КӨЛСӘҢ – КӨЛ

Электричкада бераү бик әсәрләнеп ниндидер китап укып бара – ахылдый, телен шартлата, кычкыргалап ала:
– Менә сиңа мә! Үлсәм, белмичә китәсе икәнмен! Булмас!
Вагондагы халык түзми, аның нәрсә укуы белән кызыксына.
– Орфография сүзлеге! – дип җавап бирә пассажир.

* * *

Бер ир кабакка керә дә биш рюмка аракы сорый. Аннан дүрт рюмка китертә. Аннан – өч. Аннан – ике. Соңгы ике рюмканы эчеп куйганнан соң, башын тотып уйга кала: «Бу нинди хәл инде? Азрак эчкән саен, күбрәк исерәм».

* * *

Шайтаннар фәрештәләрне футбол уйнарга чакыралар.
– Без барыбер сезне җиңәчәкбез, – диләр фәрештәләр, – чөнки иң яхшы уенчылар бездә.
– Аның каравы, бөтен хөкемдарлар безнеке, – дип җавап бирә шайтаннар.

* * *

Тегүче – заказчыга:
– Сез өйләнгәнме?
– Өйләнгән.
– Ул чакта язып куябыз: пинжәк аслыгында яшерен кесә.

* * *

Туй мәҗлесеннән соң кияү белән кәләш кунакханәгә киләләр.

Яшь ир – администраторга:
– Иртәгәгә кадәр иң яхшы бүлмә.
Ул кунак карточкасын тутырган арада, администратор кәләшнең шатлыгын уртаклаша:
– Сез бәхетле, туташ. Бу әфәнде башка вакытларда бүлмәне бер генә сәгатькә алып тора иде.

* * *

Бер ханым ветеринарга этен алып килә һәм шушы минутта ук аның койрыгын кисеп ташларга куша.
– Нәрсә булды, нигә шулай ашыгыч? – ди ветеринар.
– Иртәгә каенанам киләсе: ул барында сөенгән сыман койрык болгап йөрмәсен дим.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән авваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1580. Гомуми тираж – 5955.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 728. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы